КОЙМАКЛЫ ЯРМИНКӘ
Шимбә ярминкәләрендә азык-төлек арзан бәядән сатыла
> 2

КИСӘТӘП ТОРСАЛАР ДА...
Мошенниклардан алданмас өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга?
> 5

ДӨНЬЯ ТОТКАЛАРЫ
Танылган кешеләр – үзләренең укытучылары турында
> 6

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
«Татарча китап укучылар бүген аракы эчүчеләрдән дә түбәнрәк хәлдә»
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 144 (28726) | Сишәмбе | 5 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

КОРОНАВИРУС БИРМӘГӘН САБАК

Көн кадагында

Һәр нәрсәдән сабак алырга тиеш бугай ул кеше. Хаталарны башка кабатламас өчен кирәк бу. Әмма коронавирус күп-челекне бернәрсәгә дә өйрәтми булса кирәк. Юкса, чир йоктырып, хастаханә ятакларында сулыш алырга интегеп ятучылар кимрәк, якты дөнья белән вакытсыз хушлашучылар азрак булыр иде. Һаман да шул бер тырмага басабыз: сакланмыйбыз. Үзебезне дә, бүтәннәрне дә.

«Татар-информ»

«Кара» сентябрь

Коронавирус инфекциясе тарала гына башлаган чорда, бу чирнең никадәр мәкерле булуын беркем дә белмәде. Замана медицинасы бу зәхмәттән котылу җаен табачак дигән өмет яшәтте кешене. Хәзерге вазгыять исә уйланырга мәҗбүр итә. Уйланучылар гына күп түгел. Бу хакта уйлау – куркыта.

Роспотребнадзор мәгълүматларына караганда, Россиянең 85 төбәгенең 56сында коронавирус инфекциясеннән авыручылар саны кискен арткан. Көн саен ил күләмендә бу чирдән 800ләп кеше үлә. Пандемия башланганнан бирле үлүчеләр саны 4 млн 600 мең кешегә җиткән.

Россиядә коронавирус пандемиясенең бу «дулкын»ы иң катлаулысы булачак. Инфекционист Евгений Тимаков фикеренчә, вазгыять декабрьгә генә тотрыкланачак.

– Теләсә кайсы очракта килә торган дүртенче яки бишенче «дулкын»ны, мөгаен, җиңелрәк формада кичерербез. Авырулар күп булачак, әмма катлаулы очраклар һәр «дулкын» саен азаячак. Алты айга сузылачак бу «дулкын» исә иң авыры булачак. Бу – өченче «дулкын», ул июнь аенда башланды һәм әлегәчә дәвам итә, – диде белгеч.

Халыкның сәламәтлегеннән дә кадерлерәк берни юк. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шулай диде. Саулык турында сүз чыккан икән, чикләүләр турында да әйтмичә булмый. Вазгыять шулай киеренке сакланса, булганнарын катгыйландыру, яңаларын өстәү турында уйланачаклар.

– Көн саен кешеләрне югалтабыз. Халыкның сәламәтлегеннән дә кадерлерәк нәрсә юк. Гамәлләребезне теләсә ничек аңлатырга була, әмма сүз безнең кешеләрнең саулыгы турында бара икән, без иң катгый чаралар күрәчәкбез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республика җитәкчесен вакцина ясату мәсьәләсе борчый. Татарстан буенча 150дән артык вакцина ясату пункты эшли. Исегездә булса, июль аенда тәүлегенә 18 мең кеше вакцина ясаткан иде. Мондый күрсәткеч турында хәзер хыялланырга гына кала. Прививка кадатучылар саны ике-өч меңнән узмый. 18 яшьтән өлкәнрәк булган халыкның 30 проценты гына прививкалы. 60 яшьтән өлкәнрәкләр арасында тулысынча вакцина узган кешеләр саны 23,5 процент кына икән.

Сүз уңаеннан, Россиядә вакцина алган кешеләрнең нибары 2 проценты гына коронавирус белән авырый. Бу хакта Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко белдерде. Министр сүзләренчә, беренчел вакцинацияне илнең 50 миллионга якын кешесе үткән.

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы урынбасары Марина Трофимова белдергәнчә, коронавирустан чирләүчеләр саны икеләтә арткан. Белгечләр, бу хәл көтелгән иде, ди.

– Шунысына игътибар итәргә кирәк: 2020 елның сентябрендә авыручылар саны 712 кеше иде. Быел исә бу күрсәткеч ике тапкыр артыграк. Мондый вазгыять республикада «Һинд штаммы»ның таралуы белән дә аңлатыла. Ул, «Британ штаммы» белән чагыштырганда, 2,5 мәртәбә йогышлырак, инфекция шул рәвешле тизрәк тарала. Вакцина ясатучыларның аз булуы авыручылар санын киметүгә мөмкинлек бирми, – диде ул.

Сүз уңаеннан, коронавируска каршы вакцина ясату буенча статистика да барлык районнар өчен дә бер төрле түгел. Әйтик, алдынгылар рәтендә Яңа Чишмә (91,1 процент), Актаныш (84 процент), Ютазы (76,2 процент) районнары бар. Артта калучылар исемлегендә Питрәч, Буа, Кукмара, Яшел Үзән халкы.

Башкаларда ни хәл?

Вазгыять башка төбәкләрдә дә сөендерерлек түгел. Әйтик, күрше Башкортстанда дүшәмбедән башлап театр, музей, кинотеатр, спорт чараларына бары тик вакцина кадату яисә коронавирус белән авыруы турында белешмәсе булган кешеләр генә йөри ала. 12 октябрьдән шундый ук белешмәне сәүдә үзәкләрендә, 18еннән матурлык салоны, сауна, массаж, спа, солярий үзәкләрендә дә сорый башлаячаклар.

Мордовиядә кафе-рестораннар эшен төнге 11гә кадәр чикләячәкләр, массакүләм чаралардан да тыелырга кушалар. Моннан тыш, 65 яшьтән өлкәнрәк һәм йөкле хатын-кызларны хезмәт урыннарыннан 10 көнгә дистанцион рәвештә эшләргә җибәрүне сорыйлар.

Чувашиядә 10 октябрьдән QR-код системасы кертеләчәк. Аның ярдәмендә кафе-рестораннарга һәм мәдәни чараларга йөрү мөмкинлеге бирелә.

Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова исә, илдәге хәлне күздә тотып, барлык массакүләм чараларны тыярга кушты.

– Россиядә коронавируска бәйле хәл бик киеренке. COVID-19 белән авыручылар саны соңгы атнада ил буенча 14 процентка һәм 12 төбәктә 20 процентка артты, – диде ул. – Массакүләм чаралар бөтен ил буйлап туктатылган, алар эпидемиологик хәлгә бәйле рәвештә илнең баш санитар табибы карары нигезендә генә уздырыла. Бүген катнашучылар саны 3 меңнән артык булган чаралар үткәрергә рөхсәт алган төбәкләр юк. 1–3 мең кешегә кадәр булган чараларны ике субъектта гына үткәрергә мөмкин.

Ахыры 2 нче биттә >

Укытучы көне белән!

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Илсур ҺАДИУЛЛИН КОТЛАВЫ

Хөрмәтле укытучылар!

Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез – Укытучы көне белән тәбрик итәм! Укытучы көне ул һәр кешегә якын бәйрәм: укучылар үзләренең яраткан остазларын котлыйлар, чыгарылыш сыйныф укучылары мәктәп елларын ихлас күңелдән искә алалар.

Укытучылар хезмәтенең әһәмияте елдан-ел арта. Заман педагогларга һәрвакыт югары таләпләр куя. Хәзер укытучы инновацион цифрлы чаралар һәм укыту методикаларын яхшы белергә, җәмгыятьтә барган үзгәрешләрнең асылын аңларга тиеш. Бүген укучыларда үз Ватаннары белән горурлык тәрбияләү, үз халкының тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксындыра белү бик мөһим.

Сез балаларны мөстәкыйль фикер йөртергә, дөрес карар кабул итәргә һәм үз адымнары өчен җаваплылык хисе тәрбияләргә өйрәтәсез. Мондый максатларга үз эшләрен чын күңелдән яратучы кешеләр генә ирешә ала!

Республикабыз мәктәп белеменең югары дәрәҗәдә булуы белән билгеле, һәм бу – турыдан-туры сезнең хезмәт нәтиҗәсе, хөрмәтле укытучылар! Сезнең даими намуслы хезмәтегез укучыларга интеллектуаль һәм спорт ярышларында зур уңышларга ирешергә мөмкинлек бирә.

Тынгысыз, җаваплы һәм игелекле эшегез өчен олы рәхмәт белдерәбез. Сезгә нык сәламәтлек һәм бәхет, һөнәри үсеш һәм иҗади табышлар, яшь буынны укыту һәм тәрбияләү эшендә уңышлар телим! Хезмәтегезгә, укучыларыгызга булган мәхәббәтегез сезгә көч-илһам бирсен, нәтиҗәләрегез куанычлы булсын!

Теманың дәвамы 6 нчы биттә >

Әтиләр көне булачак

Россия Президенты Владимир Путин Әтиләр көнен билгеләп үтү турында Указны имзалады. Карар нигезендә, аны октябрь аеның өченче якшәмбесендә билгеләп үтәчәкләр. Указда әйтелгәнчә, бу көн гаилә институтын ныгыту һәм балалар тәрбияләүдә аталарның әһәмиятен арттыру максатыннан булдырылган. Указ 4 октябрьдән үз көченә керде.

2021 елда Әтиләр көне 17 октябрьгә туры киләчәк.

Керемнәр арткан

Белгечләр иң күп хезмәт хакы алган кешеләр яшәгән 100 шәһәр исемлеген атады. Рейтинг рәсми статистикада күрсәтелгән уртача хезмәт хакы һәм кулланучылар тупланмасы бәясенә (халыкның сатып алу мөмкинлеге күрсәткече. – **Ред.**) нигезләнеп төзелгән.

Татарстан башкаласы бу исемлектә – 20 нче урында. Казанда уртача хезмәт хакы 47,5 мең сум икән. Бу якынча 3,09 җыелмага җитә. Белгечләр башкалада яшәүчеләрнең кереме бер ел эчендә 12,7 процентка арткан дип тә искәртә.

Татарстанның тагын бер шәһәре исемлекнең 54 нче урынын били. Чаллыда яшәүчеләр уртача 39 мең сум акча ала икән.

Иң күп хезмәт хакы алучылар яшәгән төбәк – Салехард. Монда керем 106 мең сумны тәшкил итә.

Яңалык

Бюджет турында закон проекты әзер

Дәүләт Советында

2022 елга һәм пландагы 2023–2024 елларга Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проекты Дәүләт Советына кертелде. Документ якын араларда профильле комитетларга башлангыч карап тикшерүгә тапшырылып, парламентта республиканың төп финанс законы буенча фикер алышулар башланачак.

– Бюджет турында закон проекты Дәүләт Советына алынды, аның буенча эшлибез, – диде Бюджет, салым һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунин. – Бюджет кодексында күздә тотылган барлык процедуралар үтәлде. 2022 елга керемнәр, агымдагы елдагы белән чагыштырганда, асылда 20 миллиард сумга күбрәк күләмдә каралган. Чыгымнар – 24 миллиард сумга күбрәк. Социаль өлкә, сәламәтлек саклау, мәдәният, әйләнә-тирә мохитне саклау кебек җиде иң мөһим өлкәне финанслауга чыгымнар арттырылган. Бюджет дефицит белән төзелгән. Аны счетларда калган акча һәм өстәмә чыгымнар хисабына каплау күздә тотыла.

Аның әйтүенчә, бюджет проекты көтелмәгән чыгымнарны исәпкә алып булдырылган. «Пандемия дәвам итә. Шунлыктан бюджет проектында аның аянычлы нәтиҗәләрен мөмкин кадәр киметүгә средстволар бүлеп бирү күздә тотыла», – дип билгеләп үтте Леонид Якунин.

Бюджет проекты социаль юнәлешлелеген саклап кала. Комитет башлыгы сүзләренә караганда, хәзер проект җәмәгатьчелеккә фикер алышу өчен чыгарыла. Төрле оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр тәкъдимнәре дә исәпкә алыначак, дигән сүз бу.

Алдагы өч елга муниципаль бюджетлар исә дефицитсыз төзелгән. Монысы да – Татарстанның бюджет сәясәтенең төп үзенчәлекләреннән берсе. «Россиянең башка төбәкләрендә җирле бюджетлар коммерцияле кредитлар хисабына төзелгән. Татарстанда исә бөтенләй башкача – дефицитны каплауны республика бюджеты үз өстенә ала», – дип басым ясап әйтте Леонид Якунин.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов керткән бюджет турында закон проекты татар һәм рус телләрендә тәкъдим ителә. Документ барлыгы 4255 биттән тора. 11 октябрьдә Дәүләт Советында парламент тыңлаулары үткәреләчәк. 6 октябрьдә муниципалитетлар белән киңәшмә уздырылачак. 15 октябрьгә кадәр республиканың төп финанс законы парламентның барлык профильле комитетларында каралачак, ә 15 октябрьдә Бюджет, салым һәм финанс комитеты утырышында бюджет буенча җыелма бәяләмә чыгарылачак.

Шуннан соң гына бюджет турында закон проекты өч укылышта карап тикшереләчәк. Бюджетны беренче укылышта караганда, гомуми финанс күрсәткечләре (керемнәр һәм чыгымнар күләмнәре, дефицит күләме) расланыла.

2022 елга һәм пландагы 2023–2024 елларга Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проекты Дәүләт Советының рәсми сайтына урнаштырылачак.

Дәүләт Советына, республика бюджеты белән бергә, Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында закон проекты да кертелгән.

Татармын! Горурмын!

Айзат МИНҺАҖЕВ, каллиграф:

Әти-әни үзара урысча сөйләшәләр иде. Өч-дүрт яшь булдымы икән, балалар бакчасыннан кайткач, хәзер безнең өйдә бары тик татарча сөйләшәчәкбез, дигәнмен. Шуннан соң без татарча гына аралаша башладык. Әти-әни, сиңа нинди телдә эндәшәләр, шул телдә җавап бир, телләрне бутама, дип тә кисәтәләр иде.

(«Реальное время» интернет басмасына әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

«РИА Новости» агентлыгы Россиядә сәламәт яшәү рәвеше алып барган халык яшәгән төбәкләрне ачыклаган. Хәмер белән мавыгу, тәмәке тарту, спорт белән шөгыльләнү, хезмәт шартлары, наркомания таралу – исемлекне шушы күрсәткечләргә нигезләнеп төзегәннәр.

1. Дагыстан Республикасы
2. Чечен Республикасы
3. Адыгея Республикасы
...
15. Ставрополь крае
16. Ростов өлкәсе
17. Башкортстан Республикасы
...
31. Татарстан Республикасы
...
84. Камчатка
85. Еврей автономияле өлкәсе

Беренче чакрымнар

Казан метрополитенындагы икенче линиянең беренче участогында төзелеш эшләре бара. Бу участокта 4 станция булачак. Беренчесе – «Икеа» сәүдә үзәге, икенчесе – Фучик һәм Ломжинский урамы киселешендә, өченче станция Кол Гали һәм Завойский урамнары арасында һәм дүртенчесе Зорге һәм Фучик урамнары киселешендә төзеләчәк. Бу эш 41,1 млрд сумга төшәчәк.

«Казметрострой» җәмгыяте генераль директоры Марат Рәхимов әйтүенчә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Казан мэры Илсур Метшин ярдәме белән 2020 елда «Айсылу» тоннель комплексы «Мега» сәүдә үзәге каршындагы станциядән Фучик белән Ломжинский урамы киселешендәге станциягә кадәр сул як тоннельне казырга керештеләр. Шул ук елның октябрендә «Ләйсән» комплексы уң як тоннельне казырга тотынды. Ике станция арасы 2220 метрны тәшкил итә. Әлегә комплекслар 1710 һәм 1485 метрлы тоннель казыган.

Барлык эшләрне дә 2027 елга тәмамларга ниятлиләр.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«ПАНДОРА ТАРТМАСЫ» АЧЫЛДЫ

Дөньякүләм кризис үткән атнада кабат үзенең яңа яклары белән ачылды. Дөньяның барлык почмакларында да традициягә әйләнгән протест акцияләре кайный. Хәзер халыклар шимбә – якшәмбедә генә түгел, атна уртасында да урамнарга чыгалар. Парагвайда җирле халык белән полиция арасында бәрелешләр булып узды. Ук һәм җәяләр, рогаткалар тоткан халыкның хакимиятне яклаучы көчләр белән каршылык сәбәбе дәүләтнең җир участокларын хосусый милек итеп сатуы. Канун җирле халыкның сатылган кишәрлекләргә аяк басуын тыя. Аңлашыла инде: җирләрне акча капчыклары сатып ала, ә илнең төп халкы булган индеецларның андый мөмкинлеге юк.

Кытайда Evergrande компаниясе бинасын полиция саклый, чөнки бөлгән девелопер бер атна эчендә инде икенче тапкыр оффшор облигацияләрен түли алмады. Үткән чәршәмбедә 47,5 миллион долларлык облигацияләрне кулда тотучылар учларын җәеп калдылар. Күрәсең, төзелеш гиганты: «Кемнәргә бирәчәгебез бар, барыгызны да кичерәбез», – дип әйтергә җыена. Яшерен чыганаклар Байден, Кытай җитәкчелеге белән элемтәгә кереп, Evergrandeның бөлгенлеген булдырмауны үтенгән, диләр. Кытай гиганты рәсми дефолт игълан итсә, бөтен дөньяда хәлләр яман булачагын аңлата бу адым.

Хәлләр болай да шәп түгел. Кибет киштәләре бушаган шәһәрләр исемлегенә Брюссель да өстәлде. Германиядә халыкка электр һәм җылылык өзелгәндә, үзеңне ничек тотарга кирәклеген аңлаткан видеороликлар күрсәтәләр.

Иран – Азәрбайҗан арасында хәрби конфликт куркынычы үсә. Фарсылар Азәрбайҗанны үз җирендә Израильнең радиоэлектрон көрәш чараларын урнаштыруда гаепләүләр һәм күрше дәүләткә яулап алу белән яныйлар. Баку ягыннан конфликтка Әнкара да кушылырга мөмкин, чөнки бу илләрнең үзара алган йөкләмәләре бар. Әлегә, бәхеткә, ике як та мускуллар күрсәтү белән генә чикләнә.

Атнаның иң зур вакыйгасы «Пандора тартмасы» ачылу булды. Журналист-тикшерүчеләрнең халыкара консорциумы (ICIJ) ике ел буе 1,9 миллион яшерен финанс документын өйрәнеп, хәзерге һәм элекке ил лидерларының, йогынтылы сәясәтчеләрнең, миллиардерларның үз халыкларыннан урлап оффшорларга яшергән байлыклары турында мәгълүмат таратты. Үзләрен бик чиста итеп таныткан лидерлар зур гына байлыкларын керемнәре турындагы декларациягә кертмичә яшереп калдырганнар, зур суммадагы акчаны салымнарын түләмичә качырганнар. Исемлектә 35 ил лидеры (хәзергеләре һәм элеккеләре), дәүләт идарәсенең югары баскычындагы 330 дәрәҗәле чиновник, 130 олигарх бар. Оффшор системасының үтә яшерен булуы сәбәпле, урланган барлык суммаларны да ачыклап бетереп булмый, диләр. 2020 елда оффшорларда кимендә 11,3 триллион долларлык байлык сакланган. Кайсы ил җитәкчесенең һәм түрәләренең күпме акча шудырганын белергә теләүчеләр ICIJның мәгълүмат базасына кереп укып чыга алалар. Моны эшләү кыен түгел.

Моннан биш ел элек, 2016 елда, Журналист-тикшерүчеләрнең халыкара консорциумы «Панама досьесы» дип аталган документ игълан итеп, байтак кына ил лидерларының бармаклары үзләренә таба кәкре булуын фаш иткән иде. «Панама досьесы»н ул чакта тарихтагы иң зур саркып чыккан яшерен мәгълүмат дип атадылар һәм ул күп кенә сәясәтчеләрнең отставкасына китерде.

Россиядә

КАПЧЫКНЫ КЫСЫП БӘЙЛӘҮ

Европа һәм Кытайдан аермалы буларак, Россиягә энергетик кризис янамый. Киресенчә, газга рекордлы бәяләр фонында Россиянең ташкүмер компанияләре Көнбатышка чимал озатуны арттырырга җыеналар. Дөрес, бәяләр бездә дә үсәчәк. Федераль хөкүмәт әле яңа гына 2022–2024 елларга тарифлар сәясәтен билгеләде. Федераль бюджет проектыннан күренгәнчә, ел саен электр энергиясенә бәя 5 процентка үсәчәк. Әмма Европадагы энергетик чималга комсызлык акрынлап тагын ягулыкны кая куярга белмәү белән алышынырга мөмкин, диләр. Шуңа күрә Кремльдә Милли байлык фондындагы акчаны кысып кына тотарга, дөресрәге, тотмаска тырышалар. Үткән атна ахырында гына Кремль сайтында Путинның әмерләре исемлеге эленде. Әлегә кадәр Милли байлык фонды эчке тулай продуктның 7 процентыннан артып китсә, капчыкны чишеп, акчаны тота башлыйлар иде. Президент хәзер «түшәм»не яңа югарылыкка күтәрергә – 10 процент итәргә куша. Аның бу әмере Финанс министрлыгының Дәүләт Думасына керткән бюджет проектында искә алынган. Минфин фаразы буенча, 2025 елга ук «кара алтын»га ихтыяҗ 4–5 тапкыр кимеп, баррельнең бәясе 25 долларга кадәр төшәчәк икән. Бу 2030 еллар башында ук Россиядә бюджет кысырлыгы китереп чыгарырга мөмкин дип кисәтәләр министрлык белгечләре.

1 сентябрьгә Милли байлык фондында (ФНБ) акча күләме 8,478 триллион сум тәшкил иткән. Бу – эчке тулай продуктның 7,4 проценты кадәр. Хөкүмәт капчыктагы акчаны ишәйтү нияте белән яна. 2022–2024 елларда аңа тагын 8,203 триллион сум салмакчылар. Гомуми сумма шулай итеп 16,681 триллионга җитеп, эчке тулай продуктның 11 процентын тәшкил итәр дип фаразлыйлар. Әгәр дә иске кагыйдәләр сакланса, хөкүмәт алдагы өч елда 6 триллион сум акчаны инвестицияләргә тота алыр иде. Әмма Путин «түшәм»не күтәргәннән соң, бары тик 1,5 триллионны гына файдалану мөмкинлеге кала. Бу инде нефть һәм газ сатканнан, ташкүмер озатканнан кергән акча «үле капитал» булып капчыкта ятачак, углеводородларга бәя күтәрелү безнең тормышны аз гына да җиңеләйтмәячәк дигән сүз.

Әле Себердә өр-яңа миллионлы шәһәрләр төзисе бар. Моның өчен дә зур акча таләп ителә. Билләрне кысып буу шул сәбәпле дәвам итәр дип уйлыйк. Хәер, чиновниклар урлаган акчаны кайтарып булса, тагын бер параллель бюджет төзелер иде, мөгаен. Тик чиновниклар хәзер качып котылу әмәлен эзлиләр. «Российская газета» мәгариф министрының элекке урынбасары, соңгы эш урыны Саклык банкының вице-президенты урындыгында булган Марина Ракованың илдән качуы турында материал бирә. Аны «оешкан җинаятьче төркем составында аеруча зур күләмдә мошенниклык»та гаеплиләр. Ракова «Порше» машинасына утырып юкка чыкан. Ә менә «оешкан җинаятьче төркем»гә «Порше»да урын табылмаган. Алар тикшерү изоляторында утыралар.

ЯҢА ҖИТӘКЧЕЛӘР

Республиканың ике җирлеген хәзер яңа башлыклар җитәкләячәк. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин Мөслим һәм Түбән Камадагы район советы утырышларында катнашты.

Мөслим

Мөслим районы сессиясендә Рамил Муллин, яңа вазыйфага билгеләнү сәбәпле, башлык вазыйфасыннан китүе турында хәбәр итте.

Аның белән бер үк вакытта Мөслим районы башкарма комитеты җитәкчесе Рафаэль Демидов та отставкага китүе турында белдерде. Депутатлар ике җитәкченең дә үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатулары өчен тавыш бирде. Нәтиҗәдә район башлыгы вазыйфасы Мөслим районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Альберт Хуҗинга тапшырылды. Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына исә әлегә кеше билгеләнмәде, бәйге игълан ителде. Аңа нәтиҗәләр ясалганчы, Рафаэль Демидов элеккеге эш урынында калачак.

Түбән Кама

Моңа кадәр район башлыгы һәм шәһәр мэры вазыйфасын башкарган Айдар Метшин, Россия Дәүләт Думасы депутаты итеп сайлану сәбәпле, үз вәкаләтләрен тапшыру турында әйтте. Шулай итеп, Түбән Кама башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын башкаручы итеп Рамил Муллин сайланды.

– Башлык алмашыну – район өчен җитди вакыйга. Без барыбыз да Айдар Метшинның район белән идарә итүендәге ролен беләбез. Ул 15 еллап әлеге вазыйфаны башкарды. Бу вакыт аралыгында шактый мәсьәләләр хәл ителде, проектлар тормышка ашты, – диде Алексей Песошин. – Айдар Метшинның тәҗрибәсенә федераль дәрәҗәдә дә ихтыяҗ бар.

Утырышта башкарма комитет җитәкчесе Айдар Сәйфетдиновның отставкага китүе дә каралды.

Коронавирус бирмәгән сабак

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Вакцина ясатмый чир бетми

Вакцина ясату пунктлары буш торган арада, хастаханә ишекләре ачыла. Республика клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, хәзер вакытлыча ачылган йогышлы авырулар госпиталендә 507 кеше ята. Шуларның 126сы – авырлы хатыннар. Коронавирус йоктырган 33 кеше – реанимациядә. Ачылганда госпиталь 250 ятакка исәпләнгән иде. Вазгыятькә бәйле рәвештә, ятаклар санын арттырырга мәҗбүрләр. Госпитальләрнең чикләре коридорга кадәр сузылган: урын җитми. Бер урынга күпме сырхау туры килгәнен санап тору да кирәкми – бер ятак бушаса, аның урынына кешесе шундук табыла. Тәүлегенә коронавирус билгеләре белән 200ләп кешене кабул итәләр. Берничә дистәсендә чир расланa, алар госпитальдә кала. Статистикага күз салсаң, палаталарда ятучы сырхауларның 95 проценты – коронавируска каршы прививка кадатмаган кешеләр. Прививка ясатучылар арасында үлүчеләр юк. Табиблар кабат искәртә: вакцина чир йоктырудан гарантия бирә алмый, әмма ул аны авыр уздыру һәм үлем очракларыннан саклый.

Шушы госпиталь мөдире урынбасары Сәяр Сираҗетдинов та табиблар җилкәсенә төшкән йөкнең зур булуын әйтә. «Кешеләр күбрәк һәм авыррак чирли башлады. Биредә вакцина ясаткан кешеләр азрак, 10 проценты дисәк буладыр», – ди ул.

Түбән Кама хастаханәләренең берсендә дәваланып чыккан 60 яшьлек Гөлинә ханым да прививка кадатмаган булган. Чир кагылмас, урап узар дигән фикердә торган.

– Температура белән яттым. Аякларым йөрмәс булды. Сулыш алу да авырлашты. Өйдә генә ятып терелермен, дигән идем, булмады. Табиблар чакырттык, алып киттеләр, шундук кислородка тоташтырдылар. Үпкәләрем 70 проценттан артык зарарланган булып чыкты, – ди ул. – Прививка ясатмаган идем. Хроник чирләремә начар тәэсир итәр дип тә борчылдым, курыктым да. Аннан, бу чир миңа эләкмәс, дип тә уйладым. Тик хастаханәгә эләккәнче, аны ясату күпкә хәерлерәк.

Республика буйлап барлыгы шундый 50ләп госпиталь эшли. Аларда 5 меңгә якын ятак бар. Кайбер районнардагы хастаханәләр (мисал өчен, Әлмәт, Биектау), төп эшләрен читкә куеп, кабат коронавируслы сырхауларны дәваларга керешергә мәҗбүр. Бу исә – сәламәтлек саклау тармагына да өстәмә йөк, башка чир-сырхаулар турында уйларга да вакыт калмый дигән сүз.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Иртәрәк ачыклау мөһим

Республикада наркотиклар таралуга бәйле вазгыять катлаулы булып кала бирә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында узган Наркотикларга каршы көрәш комиссиясе утырышында шулай дип белдерде.

Президент фикеренчә, наркотикларның, шул исәптән аның яңа төрләренең таралу масштабы бөтен җәмгыять өчен зур куркыныч тудыра. «Наркотиклар ел саен меңләгән кешенең кешелеген югалтырга мәҗбүр итә, үтерә, балаларның, яшьләрнең язмышларын җимерә, гаиләләренә кайгы һәм хәсрәт китерә, җәмгыятьнең әхлакый нигезләрен какшата», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәсми саннардан күренгәнчә, бүген республикада 19 меңгә якын кеше наркомания буенча исәптә тора. Аларның саны елына якынча 2 процентка арта. Хәзерге вакытта күзәтү астында булучыларның күпчелеге 2–5 ел дәвамында наркотиклар кулланган. «Аларны дәвалау, кагыйдә буларак, нәтиҗәсез», – дип искәртте Президент. Ул наркотик кулланучыларны, бигрәк тә яшьләр арасында, мөмкин кадәр иртәрәк ачыклау системасын гамәлгә кертүне наркология хезмәтенең төп бурычы дип атады.

– Наркотик куллану буенча беренче тапкыр күзәтүгә алынучыларның барысы да диярлек республиканың эчке эшләр органнарының максатчан эше нәтиҗәсендә ачыкланган. Республиканың 19 районында һәм барыннан да бигрәк Казанда «наркомания» диагнозы куелучылар санының артуы күзәтелә, – дип искәртте Рөстәм Миңнеханов.

Агымдагы елның беренче яртыеллыгында республикада наркотик һәм психотроп матдәләр белән агулану аркасында 76 кешенең гомере өзелгән. Наркотиклар белән тәэмин итеп торучы 27 канал ябылган. Исәптә торган наркотик кулланучылар арасында балигъ булмаганнар да бар.

Анализ нәтиҗәләре белгечләрне тагын да шөбһәгә салган. Наркотиклар тарату юнәлешендә хәзер заманча коммуникация чаралары, интернет челтәре торган саен ныграк кулланыла, наркотикларның законсыз әйләнешенә күпләп яшьләр җәлеп ителә. «2020 елның ноябрендә Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин Указы белән (№ 733) 2030 елга кадәр Наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясе расланды. Аның кысасында безнең алда наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы торуның нәтиҗәлелеген арттыру бурычы тора. Барлык юнәлешләр буенча да активрак һәм кискенрәк эш итәргә кирәк», – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов комиссия утырышында.

Ярминкә

ФӘҮЗИЯ АПА КОЙМАК БЕЛӘН СЫЙЛЫЙ

КҮМӘРТӘЛӘП АЛУЧЫ АЛЫПСАТАРЛАРГА НИЧЕК КИРТӘ КУЯСЫ?

Шимбә иртәсендә башкаланың үзәк сәүдә урыны – «Агропромпарк»та узган ярминкәне карап чыгарга булдым. Кызык бит. Шәһәрнең төп ярминкәсендә шәхси һәм фермер хуҗалыклары, эре агрофирмаларда җитештерелгән продукцияләр белән чираттагы сәүдә ничек үтә? Сатып алучыларның кәефләре ничек?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Коронавирус инфекциясе таралу куркынычының көзге ярминкәләргә дә тәэсире булмый калмаган. Халык узган еллардагыдан кимрәк. Әмма моңа карап авылның шәһәргә ярдәме кимегән дип әйтеп булмый. Иртә таңнан Балтач, Саба, Нурлат районнары җитештерүчеләренең шау-гөр килеп сәүдә итүе шуны раслый. Күңелең теләгән һәр нәрсә дә бар. Итнең килограммы 320–380 сум, суган – 20, сөт – 30 сум. Бәяләр чагыштырмача арзан.

– Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының бүлек җитәкчесе Сирин Нигъмәтҗановның да кәефе күтәренке.

– Казанның 15 сәүдә мәйданында 22 районнан килгән йөзләгән фермер, 20 агрохолдинг, шул исәптән Татарстан Кулланучылар җәмгыяте, «Майский», «Ак Барс – холдинг» хуҗалыклары, кошчылык фабрикалары чагыштырмача арзан бәядән үз продукцияләрен тәкъдим итә, – ди Сирин Нигъмәтҗанов.

– Ярминкәгә 13 авыл җирлеге, «Нурлат сөте» һәм «Южная» агрофирмалары, «ВЗП Биләр», «Восток», «Заготпром» хуҗалыклары һәм фермерлар товарлары, шулай ук Раушат Сәгъдиев, Ришат Тимербулатов, Нәсибә Җумбаева, Шамил Вәлиуллин, Светлана Лизунова шәхси хуҗалыкларында җитештерелгән бәрәңге, ит, сөт, бал, йомырка суган, кишер, кәбестә һәм тагын 30дан артык продукция алып килдек. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәкъдиме белән бәяләр, үзегез күреп торасыз, кибет киштәләрендәгедән шактый арзан. Әллә шуңа, әллә башка сәбәп белән, халык кайбер төр яшелчәләрне ябырылып ала. Хуҗалыклар алып килгән 23 тоннадан артык яшелчәне берничә сәгатьтә алып та бетерделәр. Аеруча бәясе унсигез сумнан булган бәрәңге тиз сатылып бетте, – ди Нурлат районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Ришат Исхаков.

Шунысы борчый: ярминкәдәге ыгы-зыгыдан файдаланып калырга омтылучылар арта, диләр. Нурлатлылар ярминкәгә утыз машина продукция алып килгән булса, шуның дистәдән артыгы арадашчылар «һөҗүме»нә дучар булган.

– Алыпсатарлар хуҗалыклар алып килгән продукцияне ерактан каршы ала, – ди Нурлат район Советы башкарма комитетының икътисад буенча рәис урынбасары Марсим Вилданов. – Бәрәңге төялгән «КамАЗ» машиналарына алыпсатарларның игътибары аеруча зур. Барлык төр продукцияне, кем әйтмешли, капка төбендә үк югарырак бәядән күмәртәләп сатып алырга теләүчеләр бар. Без килограммын унсигез сумнан сатарга дип алып килгән бәрәңгене, кыйммәтрәк бәядән алабыз, дип торганда, кызыгучылар табылмас дип әйтеп тә булмый. Эшне тәмамлап, тизрәк кайтып китәсе дә киләдер. Тик Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгының транспорт чыгымнарын үз өстенә алуын да онытырга ярамый.

Ярминкәгә килүче барлык машиналар янына сакчы куеп булмаса да, бәрәңге бәясенең чамадан тыш үсеп китүе алыпсатарлар белән бәйле түгелме икән дигән уй да борчый.

Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров, бәрәңге бәяләре арту өчен җирлек юк, ди. Корылык нәтиҗәсендә шәхси хуҗалыкларда уңыш күләме гектарыннан уртача 155 центнер чыкса, күпләп бәрәңге үстерүче «Вятские зори» хуҗалыгында бу күрсәткеч гектарыннан – 275, «Дәүләтов» крестьян-фермер хуҗалыгында – 270, «Кырлай» җәмгыятендә гектарыннан уртача 250 центнер уңыш алына. «Бу республика халкының бәрәңгегә ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерергә мөмкинлек бирәчәк», – ди министр.

Башкалада узган ярминкәләрдә дә баштагы ыгы-зыгы кими баруы күренә. Һәрхәлдә, бәяләр төрле булса да, ярминкәләрдә бәрәңге күп. Якынча исәпләүләр буенча, казанлылар узган ярминкәләрдә 200 миллион сумлык яшелчә, шул исәптән 880 тонна бәрәңге сатып алган. Бу – узган елдагыдан шактый артык дигән сүз. Кәбестә, кишер, чөгендер, суган һәм башка төр яшелчәләрне дә быелгы ярминкәләрдә халык күбрәк сатып ала.

– Көзге ярминкәләр – авылның шәһәр халкына күрсәткән игелеге. Бәяләр ел дәвамында бераз артса да, әллә ни үсәр дип уйламыйм. Һәрхәлдә, моңа җирлек юк. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хуҗалыкларга бәяләрне тәкъдим итә алмаса да, продукция җитештерүчеләр белән бу турыда сөйләшүләр булды. Ярминкәләр үзенең социаль юнәлешен саклап калачак, – ди Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының бүлек җитәкчесе Дмитрий Яшин.

Бу кадәресе 2 октябрьдә узган ярминкәләрдә дә ачык чагылды. Нурлатлылар белән саубуллашып торганда, алар янына ашыгып-кабаланып, кулына зур савыт тоткан бер апа килеп туктады. Соңыннан белдем: биредән ерак булмаган бер йортта яшәүче Фәүзия апа икән. Нурлатлыларны коймак белән сыйларга килгән.

Моның үзенә күрә бер хикмәте бар. Авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Ришат Исхаков әйтүенчә, узган ярминкәгә бәрәңге алырга килгән Фәүзия апа акча янчыгын югалта. Аның елап торганын күргән нурлатлылар, берсен-берсе уздырып, каза күрүченең сумкасына күчтәнәч тутыра. Бу юлы үзем күрдем: башкалар коймак белән сыйланган арада, ай-ваена карамыйча, Фәүзия апаны Өлкәннәр көне белән котладылар. Әлеге күренеш күңелгә ямь өстәде. Хәтта көзнең саран кояшы да яктырак елмайган сыман булып китте.

Камил СӘГЪДӘТШИН

ЯРМИНКӘЛӘРДӘГЕ УРТАЧА БӘЯЛӘР (сумнарда/кг)

Суган, кишер, кабак, кәбестә – 25
Чөгендер – 20
Бәрәңге – 20–35
Үгез ите – 320–380
Куян ите – 350
Ат ите – 350
10 данә йомырка – 50–75
Солы ярмасы – 10
Карабодай ярмасы – 40–60

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 36 (I өлеш), «һәм салым түләүчеләрнең алардан файдалану нигезләре» сүзләрен «, аларны куллану нигезләре һәм тәртибе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 58-ТРЗ

2022 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 227^{1} статьясы нигезендә 2022 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны 2,0 итеп билгеләргә.

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм физик затлар керемнәренә салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 59-ТРЗ

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында»;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Хокукый җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26^{3-3} статьясы нигезендә түбәндәгеләрне билгели:

1) түбәндәге Татарстан Республикасы законнары проектларының, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актлары проектларының (алга таба – норматив хокукый актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибен:

а) дәүләт контроле (күзәтчелеге), административ җаваплылыкка тарту, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр бирү, аккредитацияләү, продукциянең тәңгәллеген бәяләү, бәяләүләрнең һәм экспертизаларның башка рәвешләре кысаларында үтәлеше бәяләнә торган эшкуарлык эшчәнлеген һәм башка икътисадый эшчәнлекне башкаруга бәйле мәҗбүри таләпләрнең (алга таба – мәҗбүри таләпләр) яңаларын билгеләүче, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче яисә юкка чыгаручы;

б) эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычларның һәм тыюларның яңаларын билгеләүче, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче яисә юкка чыгаручы;

в) эшкуарлык эшчәнлеген һәм башка икътисадый эшчәнлекне башкару мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын бозган өчен җаваплылык билгеләүче, элек билгеләнгәнен үзгәртүче яисә юкка чыгаручы;

2) Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларында (алга таба – норматив хокукый актлар) булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү тәртибен;

3) эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы, мәҗбүри таләпләре булган актлардан тыш, норматив хокукый актларга экспертиза ясау тәртибен (алга таба – норматив хокукый актларга экспертиза) .»;

2) 2 статьяның 2 өлешендә «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге» сүзләрен «эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 статьяның 2 өлешендә «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге» сүзләрен «эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

4) 3^{1} статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3^{1} статья. **Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү тәртибе**

1. Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү тәртибе, «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү принципларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү җайга салучы орган тарафыннан уздырыла.

3. Җайга салучы орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә мәҗбүри таләпләрне кертү максатларына ирешү турындагы доклад әзерли. Әлеге тәртип белән шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертү максатларына ирешү турындагы докладны карау һәм мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актның гамәлдәге чорын озынайту турында яисә мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру турында карар кабул итү тәртибе билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 60-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 6^{1} һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6^{1} статьяда «Россия Федерациясенең бухгалтерлык хисабы турындагы законнарында аның мәҗбүри нөсхәсен» сүзләрен «, әгәр күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыятьләр мондый хисаплылыкны «Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында каралган дәүләт мәгълүмат бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы ресурсын (алга таба – дәүләт мәгълүмат бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы ресурсы) формалаштыру максатларында тапшыру бурычыннан азат ителгән булса, Россия Федерациясенең бухгалтерлык хисабы турындагы законнарында аның мәҗбүри нөсхәсен тапшыру өчен билгеләнгән срокта, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга, «тапшыру өчен билгеләнгән срокта» сүзләрен төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыятьләр дәүләт мәгълүмат бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы ресурсын формалаштыру максатларында еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырган очракта, вәкаләтле башкарма хакимият органы мондый хисаплылыкны, бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, дәүләт мәгълүмат ресурсыннан ала.»;

2) 11 статьяның сигезенче абзацында «бухгалтерлык балансын, табышын һәм зыяннары исәпләрен» сүзләрен «еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 61-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 20^{1} пункт өстәргә:

«20^{1}) җирлек торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларны, алар составында булдырыла торган участок урманчылыкларын төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук җирлек торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 20^{2} пункт өстәргә:

«20^{2}) җирлек торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше чараларын үткәрү;»;

2) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 26^{2} пункт өстәргә:

«26^{2}) шәһәр округы торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларны, алар составында булдырыла торган участок урманчылыкларын төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 26^{3} пункт өстәргә:

«26^{3}) шәһәр округы торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше чараларын үткәрү;».

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 62-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 пунктында «шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга, «корылмалар» сүзеннән соң «, шулай ук крестьян (фермер) хуҗалыклары үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалана торган җир кишәрлекләрендә төзү, реконструкцияләү һәм куллану рөхсәт ителә торган торак йортлар» сүзләрен өстәргә;

2) 14 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җир өсте су объектлары урнашкан җирләр су фонды җирләре булып тора.»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әгәр су объектлары тулысынча авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр һәм (яисә) башка категорияләрдәге җирләр чикләрендә урнашкан булса, мондый җирләр су фонды җирләренә керми.»;

3) 21 статьяның 2 пунктындагы беренче абзацында «урман хуҗалыгы, урман сәнәгате, су, балык хуҗалыклары оешмалары, аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар» сүзләрен «урман комплексы, су, балык, аучылык хуҗалыклары оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

4) кушымтаның 2 пунктындагы 5 пунктчасының беренче абзацында «(җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{6} статьясының 2 пунктындагы 3^{1} пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2 статья

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең әлеге статьяда башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 63-ТРЗ

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә медицина тикшерүләрне үткәрергә вәкаләтле медицина оешмалары исемлеген билгеләү.»;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге статьяның 1 өлешендәге унынчы абзацында күрсәтелгән вәкаләт Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла.»;

2) 5 статьяның 3 өлешендә:

а) беренче абзацта «профилактик» сүзен төшереп калдырырга;

б) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Медицина тикшерүләре уздыру, хисаплылык алып бару, шәхси медицина кенәгәләрен, шул исәптән электрон документ рәвешендә, исәпкә алу һәм аларны хезмәткәрләргә бирү тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон 2021 елның 31 октябрендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 64-ТРЗ

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары составында Татарстан Республикасы милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан, кыйммәтле металларның һәм кыйммәтле ташларның дәүләт запасларын реализацияләүдән керемнәр, шулай ук инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджет кредитлары һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчалар, шул исәптән Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары, кимү, банк депозитларыннан акчаларны кире кайтарудан алына торган акчалар һәм банк депозитларына урнаштырыла торган акчалар арасындагы аерма расланган очракта, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләрдән күрсәтелгән керемнәр суммасы, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчалар, шул исәптән Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары кимү чикләрендә, банк депозитларыннан акчаларны кире кайтарудан алына торган акчалар һәм банк депозитларына урнаштырыла торган акчалар арасындагы уңай аерма чикләрендә, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагын инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджет кредитлары тәшкил иткән инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә юнәлтелгән бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә артыграк булырга мөмкин.»;

2) 25 статьяның 3 пунктындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган очракларда, товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә хисап финанс елында түләнергә тиешле бу дәүләт контрактларын түләүгә бюджет ассигнованиеләренең, максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә хисап финанс елында бирелгән максатчан билгеләнешле субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бирүгә бюджет ассигнованиеләренең, субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә хисап финанс елында бирелгән күрсәтелгән субсидияләрне юридик затларга бирүгә бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәреләләр;»;

3) 37 статьяда:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Принципалның кредит (заем, шул исәптән облигацияле заем) буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) гарант тарафыннан түбәндәге очракларда гына кире алынырга тиеш:

1) төп йөкләмәнең Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясендә (муниципаль гарантиядә) күрсәтелгән, гарантның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган шартлары гарантның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка үзгәртелгәндә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) белән тәэмин ителгән кредит (заем, шул исәптән облигацияле заем) акчалары максатчан файдаланылмаганда.»;

б) 27 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Принципалның кредит (заем, облигацияле заемнан тыш) буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) кредиторның (заем бирүченең) күрсәтелгән кредит (заем) акчаларының максатчан файдаланылуын тикшереп торуны үзе тарафыннан башкару бурычлары кредит шартнамәсендә (заем шартнамәсендә) һәм (яисә) күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) бирү турындагы шартнамәдә билгеләнгән булса бирелә.»;

4) 43 статьяның дүртенче абзацына «, федераль законнарда билгеләнгән очракларда, федераль территорияләрнең гавами хакимияте органнарына тапшырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль территорияләр бюджетларына субвенцияләр»;

5) 44^{4} статьяда:

а) 3 пунктның җиденче абзацында «субсидияләр бирү,» сүзләрен «субсидияләр,» сүзенә алмаштырырга, «субсидияләрдән тыш,» сүзләреннән соң «әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезендә бюджет ассигнованиеләре артуга бәйле рәвештә бирелә торган субсидияләр бирү» сүзләрен өстәргә;

б) 4 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«Әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезендә бюджет ассигнованиеләре артуга бәйле рәвештә хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында бирелгән субсидияләрне муниципаль берәмлекләр арасында кабат бүлү башкарылмый.»;

икенче – дүртенче абзацларны тиешенчә өченче – бишенче абзацлар дип санарга;

в) 4^{1} пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган субсидияләрне бирү турында килешүләр төзү чираттагы финанс елының 15 февраленә кадәр башкарыла, моңа Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы нигезендә бюджет ассигнованиеләре бирү каралган һәм күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча төзелә торган субсидияләр бирү турындагы килешүләр керми.

Субсидия бирү турында килешү муниципаль берәмлекләр арасында субсидияләр бүлү билгеләнгән тәртиптә расланган сроктан ким була алмаган срокка төзелә.

Әлеге пунктның икенче абзацында каралган сроклар бозылган очракта, агымдагы финанс елына тиешле максатларга каралган Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирү турында килешү төзелмәгән субсидия күләмендә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.»;

6) 44^{5} статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының аларга ярашлы рәвештә кабул ителә торган бүтән норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә түбәндәге очракларда бирелә:

1) җирле үзидарә органнарының федераль законнар һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары белән җайга салынмаган вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу, шул исәптән тулы күләмдә, очрагында;

Ахыры 4 нче биттә >

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Ахыры. Башы 3 нче биттә >

2) җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу, шул исәптән тулы күләмдә, очрагында;

3) финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондлары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды булган бюджет ассигнованиеләрен бирү очрагында;

4) Татарстан Республикасы законнарында (чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законыннан һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законыннан тыш) билгеләнгән очракларда;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда.»;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) аның нигезендә чираттагы финанс елының 15 февраленә кадәр кабул ителгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән раслана, моңа түбәндәге башка бюджетара трансфертлар керми:

1) финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондларының, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган;

2) Татарстан Республикасы бюджетында башкача резервланган, агымдагы финанс елының 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары белән бүленергә тиешле бюджет ассигнованиеләре исәбеннән бирелә торган;

3) Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы нигезендә каралган һәм күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары белән бүленергә тиешле бюджет ассигнованиеләре исәбеннән бирелә торган;

4) муниципаль берәмлекләрне бүләкләү максатларында, шул исәптән социаль-икътисадый үсешнең иң яхшы күрсәткечләренә ирешкән өчен һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең иң яхшы тәҗрибәләре өчен бирелә торган;

5) җирле бюджетларның фактта тотылган чыгымнарын каплауга бирелә торган;

6) күләмнәре федераль бюджеттан һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджетыннан кемнәр алынуга бәйле булган;

7) конкурс нигезендә бүленә торган.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 4^{1} һәм 4^{2} пунктлар өстәргә:

«4^{1}. Әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезендә бюджет ассигнованиеләре артуга бәйле рәвештә хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында бирелгән башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында кабат бүлү башкарылмый.

Бу вакытта муниципаль берәмлекләр арасында бүленмәгән башка бюджетара трансфертларның күләмен план чорының беренче елына расланган тиешле башка бюджетара трансфертларның гомуми күләменнән 5 проценттан артмаган күләмдә һәм план чорының икенче елына расланган күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларның гомуми күләменнән 10 проценттан артмаган күләмдә расларга рөхсәт ителә.

4^{2}. Әгәр Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен (кагыйдәләрен) билгели торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актларында башка бюджетара трансферт бирү турында килешү төзү каралган булса, мондый килешүләр чираттагы финанс елының 15 февраленә кадәр төзелә, моңа Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы нигезендә бюджет ассигнованиеләре бирү каралган һәм күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешүләр керми.

Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр һәм күрсәтелгән килешүләргә үзгәрешләр кертүне яисә аларны өзүне күздә тоткан аларга өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган типлаштырылган формалар нигезендә төзелә.

Башка бюджетара трансферт бирү турында килешү муниципаль берәмлекләр арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү билгеләнгән тәртиптә расланган сроктан ким була алмаган срокка төзелә.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган сроклар бозылган очракта, агымдагы финанс елына тиешле максатларга каралган Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирү турында килешү төзелмәгән башка бюджетара трансферт күләмендә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.»;

7) 44^{6} статьяда:

а) 10 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«Хисап финанс елында бирелгән һәм агымдагы финанс елында бирелүе әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезендә бюджет ассигнованиеләре артуга бәйле булган субвенцияләрне муниципаль берәмлекләр арасында кабат бүлү башкарылмый.»;

икенче – дүртенче абзацларны тиешенчә өченче – бишенче абзацлар дип санарга;

б) түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. Әлеге статья нигезләмәләре, федераль законнарда билгеләнгән очракларда, федераль территорияләр тарафыннан гамәлгә ашырылуы өчен тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган федераль территорияләрнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль территорияләр бюджетларына субвенцияләр биргәндә кулланыла.»;

8) 53 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1^{1} пунктча өстәргә:

«1^{1}) Россия Федерациясенең илкүләм үсеше максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлеге юнәлешләрен билгели торган документларга;»;

9) 60^{1} статьяда:

а) 3 пунктның 1 һәм 2 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) 3^{1} пунктның 4 һәм 5 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

10) 77 статьяда:

а) 3 пунктта:

сигезенче абзацта «хәбәрнамә алынган,» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирелгән,» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацта «арттырган очракта» сүзләреннән соң «, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242^{22} статьясы нигезендә бирелгән йөкләмәләрне үтәлмәгән казнадан тәэмин итү суммасына» сүзләрен өстәргә;

унбишенче абзацта «сигезенче һәм унынчы» сүзләрен «сигезенче, унынчы һәм унберенче» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3^{2} пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре, шулай ук әлеге Кодексның 44^{4} статьясындагы 4^{1} пункты һәм 44^{5} статьясындагы 4^{2} пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган бюджетара трансфертлар бирүгә бюджет ассигнованиеләре арттырылган очракта.»;

сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга;

11) 93^{1} статьяның 4 пунктында «бюджет процессында катнашучы булып тормаган, бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр булмаган юридик затларның» сүзләрен «бюджеттан акчалар алучыларның акчалары белән операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларындагы һәм казначылык аша эшли торган катнашучыларның» сүзләренә алмаштырырга;

12) 97^{1} статьяда:

а) исемендә «төзү» сүзеннән соң «, тапшыру һәм раслау» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктның беренче абзацында «(алга таба – бюджет акчаларының баш администраторлары)» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 97^{2} статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы «Электрон бюджет» җәмәгать финанслары белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Татарстан Республикасы финанс министрының (вәкаләтле вазыйфаи затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында бюджет хисаплылыгын (дәүләт серенә кертелгән йә конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган хисаплардан тыш) тапшыра.».

2 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 53^{1} статьясының, 77 статьясының 3 пунктындагы уналтынчы абзацының (дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү өчен каралган бюджет ассигнованиеләрен киметү өлешендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) гамәлдә булуын 2022 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3 статья

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең бүтән сроклары каралган нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 8 пункты, 10 пунктының «а» пункчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлары, 11 пункты, 12 пунктының «а» пунктчасы, 13 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көчләренә керә.

3. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44^{4}, 44^{5}, 44^{6}, 60^{1} статьялары нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә), 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 65-ТРЗ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); № 36 (I өлеш); № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «һәм срокларын» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм салым түләүчеләрнең алардан файдалану нигезләрен» сүзләрен

«, салым түләүчеләр тарафыннан аларны куллану нигезләрен һәм тәртибен» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяның 2^{1} өлешендә «2020 һәм 2021» сүзләрен «2020 – 2023» саннарына алмаштырырга;

3) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Салым түләү тәртибе**

Салым түләүчеләр салым чоры тәмамланганнан соң салым, шулай ук хисап чоры нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән срокларда салым буенча аванс түләүләре түлиләр.».

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 66-ТРЗ

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы өстәмә килешүне раслау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен Татарстан Республикасына бирелгән бюджет кредиты буенча бурычның реструктурлаштыру датасына түләнеп бетмәгән калдыклары чикләрендә Татарстан Республикасының бюджет кредиты буенча Россия Федерациясе каршындагы йөкләмәләрен (бурычларын) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы һәм «2021 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 июнендәге 1029 номерлы карары нигезендә үткәрелгән реструктурлаштыру кысаларында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән 2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы 2 063 527 000 сумлык Өстәмә килешүне әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 67-ТРЗ

«Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында
2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә
2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы
өстәмә килешүне раслау хакында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында
2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә 1 номерлы

ӨСТӘМӘ КИЛЕШҮ

Мәскәү шәһәре 2021 елның «1» июле

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2020 елның 10 декабрендәге 1088 номерлы боерыгы нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлеше һәм «2021 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру кагыйдәләрен раслау турында» (алга таба – Кагыйдәләр) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 июнендәге 1029 номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешү төзеделәр.

1. Яклар әлеге Өстәмә килешү төзелгән датага Заемщикның 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы Килешү (алга таба – Килешү) нигезендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән бюджет кредиты буенча йөкләмәсе (бурычлары) 2 063 527 000 (ике миллиард алтмыш өч миллион биш йөз егерме җиде мең) сум дип раслыйлар, шул исәптән:

а) төп бурыч буенча – 2 063 527 000 (ике миллиард алтмыш өч миллион биш йөз егерме җиде мең) сум;

б) бурычны реструктурлаштыру датасына бюджет кредитыннан фактта файдалану срогы өчен исәпләнгән процентлар буенча – 0 (ноль) сум.

2. Әлеге Өстәмә килешү үз көченә кергән датадан Заемщикның әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән йөкләмәләре (бурычлары) берләштерелә һәм реструктурлаштырылган бурыч булып тора.

Реструктурлаштырылган бурычны каплау Заемщик тарафыннан 2021 елдан 2029 елга кадәр (2029 елны да кертеп) түбәндәге түләү срокларында башкарыла: 2021 – 2024 елларда ел саен бурыч суммасының 5 проценты күләмендә, 2025 – 2029 елларда, вакытыннан алда түләп бетерү мөмкинлеге белән, калган бурыч суммасын ел саен тигез өлешләр белән әлеге Өстәмә килешүгә кушымтада бирелгән график нигезендә, график Өстәмә килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора (алга таба – график).

Реструктурлаштырылган бурыч Заемщик тарафыннан ел саен, тиешле елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнә.

3. Реструктурлаштырылган бурычның калган өлешенә, 2021 елның 2 июленнән алып реструктурлаштырылган бурычны түләү йөкләмәсен тулы күләмдә үтәү көненә кадәр, еллык 0,1 процент күләмендә түләү (алга таба – кичектереп түләгән өчен процентлар) исәпләнә.

2021 – 2029 елларда кичектереп түләгән өчен процентларны түләү ел саен, тиешле елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, реструктурлаштырылган бурычны түләү белән бергә гамәлгә ашырыла.

Реструктурлаштырылган бурычны вакытыннан алда түләп бетергән очракта, кичектереп түләгән өчен процентларны түләү вакытыннан алда түләп бетерү белән бергә гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта вакытыннан алда түләү башкарыла торган ел өчен процентлар яңадан саналмый.

Кичектереп түләгән өчен процентларны түләгәндә Заемщик исәп-хисап документының 104 юлында бюджет классификациясенең тиешле кодын күрсәтә.

4. Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән бюджет кредиты буенча бурычларны реструктурлаштыру Заемщик тарафыннан түбәндәге йөкләмәләрне кабул итү шарты белән үткәрелә:

а) Россия Федерациясе субъекты бюджетының 2021 елда бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә вакытлыча тотылмый торган акчаларын 2021 – 2024 елларда «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясындагы 3 өлеше нигезендә билгеләнә торган яңа инвестиция проектларын (алга таба – яңа инвестиция проектлары) гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан бюджет инвестицияләрен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан каралган тәртиптә инфраструктура объектларында гамәлгә ашыруга юллау.

Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан вакытлыча тотылмый торган, әлеге пунктчаның беренче абзацында каралган максатларга юнәлдерелергә тиешле акчалар күләме 2021 елда бюджет кредиты буенча бурычны түләү графигы нигезендә билгеләнә торган реструктурлаштырылган бурычны түләү, бюджет кредитыннан файдаланган өчен Килешүгә кушымта итеп бирелгән процентларны түләү күләме һәм Кагыйдәләрнең 8 пунктындагы беренче абзацы һәм әлеге Өстәмә килешүнең 2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә билгеләнә торган реструктурлаштырылган бурычны түләү күләме арасындагы аерма буларак исәпләнә һәм 1 960 350 650 (бер миллиард тугыз йөз алтмыш миллион өч йөз илле мең алты йөз илле) сум тәшкил итә;

б) әлеге Өстәмә килешүне Россия Федерациясе субъекты законы белән раслау (чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында законнан тыш) һәм аңа кул куелган көннән алып 6 ай эчендә Россия Федерациясе субъекты законы күчермәсен Кредиторга тапшыру;

в) чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында закон расланганнан соң, ел саен, 14 эш көне эчендә Кредиторга, реструктурлаштырылган бурычны түләүгә һәм (яисә) кичектереп түләгән өчен процентларны түләүгә юнәлдерелә торган акчалар суммасын күрсәтеп, чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законнан өземтә бирергә. 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законнан күрсәтелгән өземтә 2021 елның 30 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш;

г) реструктурлаштыруның әлеге пунктның «а»–«в» пунктчаларында каралган шартларын үтәү турында мәгълүматны ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 25 февраленнән дә соңга калмыйча, реструктурлаштырылган бурычны тулысынча каплап бетергәнче Кредиторга тапшыру.

5. Заемщик тарафыннан график бозылган очракта, Заемщик йөкләмәләрне үтәү срогы башланган датага Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставканың 1/300 күләмендә пеня түли, пеня йөкләмәләрне үтәү кичектерелгән һәр көн өчен бюджет кредитлары буенча реструктурлаштырылган бурычның гомуми күләменнән чыгып исәпләнә.

Реструктурлаштырылган бурыч һәм (яки) кичектереп түләгән өчен процентлар Графикта билгеләнгән срок җиткәннән соң 14 эш көне узганчы Заемщик тарафыннан түләнмәгән очракта, капланмаган реструктурлаштырылган бурыч һәм шулай ук кичектереп түләгән өчен тиешле графикта конкрет датага саналган процентлар Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы капланырга тиеш. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пеня да түләнергә тиеш.

Заемщик тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләрнең 2024 ел йомгаклары буенча үтәлешен бәяләгәндә, хисап елында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган максатларга юнәлдерелергә тиешле Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары, тотылмый калган акчаларны яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрү өлешендә, күрсәтелгән максатларга 2021 – 2024 елларда юнәлдерелгән Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары күләменнән чыгып билгеләнә.

Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләр 2021 – 2024 ел йомгаклары буенча Заемщик тарафыннан үтәлмәгән очракта, Заемщик график нигезендә 2025 елда реструктурлаштырылган бурычны һәм кичектереп түләгән өчен процентларны түли, шулай ук вакытыннан алда, 2025 – 2027 елларда, ел саен тигез күләмнәрдә, бурычны алдан каплауны күздә тоткан графикта билгеләнгән срокларда, яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиешле тотылмый калган акчалар күләмендә бурычны түли.

Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләрнең 2021 – 2024 ел йомгаклары буенча Заемщик тарафыннан үтәлешен бәяләгәндә, бюджет кредитлары буенча әлеге пунктның дүртенче абзацы нигезендә вакытыннан алда түләнергә тиешле реструктурлаштырылган бурыч күләме, Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган тотылмый калган акчалар күләме чикләрендә, 2021 – 2024 елларда фактта тотылган чыгымнар суммасына, шулай ук 2022 – 2024 елларда Россия Федерациясе субъекты тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктурлаштырылган бурычны түләүгә җибәрелгән акчалар суммасына кими.

Заемщик тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «б» пунктчасында каралган нигезләмәләр бозылган очракта, капланмаган реструктурлаштырылган бурыч, шулай ук кичектереп түләгән өчен исәпләнгән процентлар Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы түләнергә тиеш.

Заемщикның Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «в» һәм «е» пунктчаларын һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «в»-«г» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының гамәлләре (гамәл кылмаулары) күрсәтелгән йөкләмәләрне бозуга китергән вазыйфаи затларына карата Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе) тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануга китерә.

Кредитор Заемщиктан бюджет кредитлары буенча үз вакытында түләнмәгән бурычларны һәм (яисә) бюджет кредитлары буенча реструктурлаштырылган бурычны каплау буенча үтәлмәгән йөкләмәләр өчен пеня түләттерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны куллана.

6. Килешүнең әлеге Өстәмә килешүдә каралмаган, аңа каршы килми торган калган шартлары үзгәрми һәм Яклар алар буенча үзләренең йөкләмәләрен раслыйлар.

7. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге Өстәмә килешү, кушымтаны да кертеп, һәр Як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә, 6 биттә төзелде.

Якларның урнашу урыннары һәм адреслары

Кредитор: Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Ильинка урамы, 9 йорт, Мәскәү шәһәре, 109097.
Заемщик: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Ирек мәйданы, 1 йорт, Казан шәһәре, 420060.

Якларның имзалары

Кредитордан:	**Заемщиктан:**
Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары	Татарстан Республикасы Премьер-министры
Л.В. Горнин	А.В. Песошин
_______________ (имза)	_______________ (имза)
М.У.	М.У.

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында
калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын
каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредиты бирү турында
2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022
номерлы килешүгә 2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы
Өстәмә килешүгә
кушымта

Реструктурлаштырылган бурычны каплау һәм
кичектереп түләгән өчен процентларны түләү
графигы

Кайтару срогы		Реструктурлаштырылган бурыч (сум)	Реструктурлаштырылган бурычны кайтару суммасы (сум)	Кичектереп түләгән өчен процентлар (сум)	Түләү (барлыгы) (сум)
2021 ел	30.11.2021	2 063 527 000,00	103 176 350,00	1 025 827,32	104 202 177,32
2022 ел	30.11.2022	1 960 350 650,00	103 176 350,00	1 951 587,73	105 127 937,73
2023 ел	30.11.2023	1 857 174 300,00	103 176 350,00	1 848 411,38	105 024 761,38
2024 ел	29.11.2024	1 753 997 950,00	103 176 350,00	1 744 977,07	104 921 327,07
2025 ел	28.11.2025	1 650 821 600,00	330 164 320,00	1 620 971,13	331 785 291,13
2026 ел	30.11.2026	1 320 657 280,00	330 164 320,00	1 292 615,93	331 456 935,93
2027 ел	30.11.2027	990 492 960,00	330 164 320,00	962 451,61	331 126 771,61
2028 ел	30.11.2028	660 328 640,00	330 164 320,00	632 363,91	330 796 683,91
2029 ел	30.11.2029	330 164 320,00	330 164 320,00	302 122,97	330 466 442,97
Барлыгы	**х**	**х**	**2 063 527 000,00**	**11 381 329,05**	**2 074 908 329,05**

Якларның имзалары

Кредитордан:	**Заемщиктан:**
Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары	Татарстан Республикасы Премьер-министры
Л.В. Горнин	А.В. Песошин
_______________ (имза)	_______________ (имза)
М.У.	М.У.

ЮРИСТ РОМАН АРХИПОВ: «ЙӨЗӘ БЕЛМӘСӘҢ, СУГА КЕРМӘ!»

Кисәтә торалар, алдана торабыз. Әле газетабызның алдагы саннарының берсендә генә телефон аша эш итүче мошенниклар кулыннан алданган ялгыз ана турында язып чыккан идек. Аннан соң бер-бер артлы янә шундый алдану очраклары турында хәбәрләр ишетергә туры килде. Дөрес булса, кырыгалдарлар хәзер күбебезнең төп ярдәмчесенә әйләнгән дәүләт хезмәтләре порталы аша да халыкны төп башына утырта башлаган. Бу сүзләрдә ни дәрәҗәдә хаклык бар? Кырыгалдар корбаны булмас өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? Юрист Роман АРХИПОВ белән кабат шушы борчыган мәсьәлә турында сөйләшәбез.

:: Роман Радикович, соңгы арада мошенниклар дәүләт хезмәтләре порталы аша да халыкны төп башына утырта башлаган дигән хәбәр таралды...

– Әйе, соңгы арада андый хәлләр дә күзәтелә башлады шул. Кырыгалдарлар биредә дә шул ук схема буенча эш итә. Дәүләт хезмәтләре порталында шәхси бите булган кешегә кемдер шалтырата да, порталдагы мәгълүматларның читкә таралуын әйтеп, кешенең шәхси мәгълүматлары читкә очмасын өчен тиз арада аның телефонына килгән парольне атавын сорыйлар. Кеше парольне әйтүгә, дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси битен җимереп, аның турында бөтен мәгълүматны, шул исәптән банк карталарындагы акчаны үзләштерәләр.

:: Соңгы арада тагын нинди алдау ысуллары популяр?

– Алдакчылар – бик «иҗади» халык. Кешеләрне алдауның яңадан-яңа ысулларын уйлап табып кына торалар. Соңгы арада алар халыкны күбрәк акчасын төрле проектларга, аерым алганда, финанс пирамидаларына кертергә өндәп, төп башына утыртырга тырышты. Халыкны алдауның элек-электән килгән традицион ысуллары да актив кулланыла алар. Кешене банкның куркынычсызлык хезмәтеннән, йә булмаса полициядән дип шалтыратып төп башына утырту – шундый иң киң таралган алымнарның берсе. Машина сатып алганда алдану очраклары да күп. Соңгы арада автосалоннар эшчәнлегенә шикаять белдерүчеләр саны артты. Алар күбесенчә биредә үзләренә ниндидер өстәмә хезмәтләр, җиһазларны көчләп тагарга җыенуларыннан зарлана. Бу турыдан-туры кырыгалдарлык очраклары түгел, билгеле. Әмма араларында мошенниклык дип саналырлык мисаллар шактый.

:: Хәзерге вакытта автосалоннарда иң киң таралган алдау мисалын китерегезче.

– Ниндидер өстәмә хезмәтләр, җиһазлардан башка гына машина сатудан баш тарткан автосалоннардан ерак торырга киңәш итәр идем. Казанда әнә шул яктан данлы чыккан бер автосалон бар. Алар килешүне бик оста итеп төзетә. Кеше автосалонга килә дә сату-алу килешүе төзи. Документта автосалонның аңа, мисал өчен, 50 мең сум ташлама ясавы күрсәтелгән була. Гади кеше моны күреп сөенә, билгеле. Миңа шундый зур ташлама ясыйлар, янәсе. Шатлыгыннан килешүдәге башка шартларны укып та бетерми. Анда исә ул бу ташламаны ниндидер өстәмә хезмәтләр күрсәтүгә ризалыгын белдереп, тагын берничә өстәмә килешү төзегән очракта гына ала алачак диелгән була. Бу шартны үтәмәгән очракта, кеше теге ташлама бәясен автосалонга кире кайтарырга тиеш була.

:: Телефон аша сөйләшкәндә синең нәкъ менә кырыгалдар белән сөйләшүеңне ничек чамаларга мөмкин?

– Үз тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтә алам: кырыгалдарлар сата торган иң беренче билге – үзсүзлелек. Мошенник, гадәттә, кешенең өстеннән торып, уйларга бер минут та вакыт бирмичә, аңа тиз арада нидер эшләргә куша, ашыктыра. Шуңа күрә сезгә кемдер шалтыратып, тиз арада ниндидер шәхси мәгълүмат бирүегезне, ниндидер операция башкаруыгызны сораса, шикләнергә җирлек бар. Андый чакта бу кеше белән, гомумән, сөйләшмичә трубканы куюдан да яхшысы юк.

:: Мошенник белән сөйләшкәндә үз-үзеңне ничек тотарга кирәк?

– Әйткәнемчә, кырыгалдарлар белән бөтенләй сөйләшмәвең хәерле. Сөйләшкән очракта үзеңне тыныч тотарга, аларга берни аңлатмаска, дәлилләмәскә кирәк. Аларның соравына сорау белән җавап бирегез. Гомумән, кырыгалдарларга сорау белән яки «юк» дип кенә җавап бирергә ярый. Аларга беркайчан да «әйе», «ярар» диярга ярамый. Сезгә банкның куркынычсызлык хезмәтеннән дип шалтыраталар икән, банкның «кайнар элемтә» номерын җыеп, сезгә яңа гына фәлән номердан шалтыратып, банк исеменнән фәлән хезмәт тәкъдим итүләрен әйтегез, ачыклык кертүләрен сорагыз.

:: Хәзер күпләр финанс пирамидаларына кереп алдана, дидегез. «Френдекс», «Альтарес», «Финико» корбаннары акчасын кире кайтаруга өмет итә аламы?

– Финанс пирамидасы ябылган очракта акчаны кире кайтару мөмкин түгел диярлек. Ник дигәндә, безнең законнар технологияләр үсеше артыннан өлгерә алмый. Элегрәк финанс пирамидалары ниндидер исәп-хисап счетына традицион валютадагы «тере» акча салу юлы белән эшли иде. Хәзер мондый шикле оешмаларга нигез салучылар криптовалюта белән эшләүгә күчте. Бу очракта кемнеңдер кемгәдер мондый төр акчаны күчерүен ачыклавы да, исбатлавы да бик кыен. Теге яки бу финанс пирамидасына нигез салган кешеләр, бу эшкә тотынганда ук, аның тиз арада ябылачагын да, акчаны кире кайтарып булмасын да, үзләренә карата җинаять эше ачылачагын да бик яхшы белә. Аларны эзләп тапкан очракта, зыян күрүчеләргә акчаны оештыручыларның милкеннән кайтарачаклары да көн кебек ачык. Шуңа күрә, тикшерү башлагач, финанс оешмаларының төп оештыручылары исемендә берни дә булмый. Шуңа хәзер аларның уң, сул – әллә ничәнче кул ярдәмчеләрен дә кулга ала башладылар. Зыян күрүчеләргә акчаны шуларның милкеннән кайтарырга җыеналар. Ә аннан үзеңә өлеш чыксын дисәң, үзеңнең теге яки бу финанс пирамидасы тарафыннан зыян күрүеңне белгертеп язылган гаризаң, мотлак расларлык дәлилләрең (шәхси битнең скриншот рәсеме, крипто исәп-хисап счеты турында мәгълүмат һ.б.) булырга тиеш. Бу юл белән зыян күрүчеләргә акчаны кайтарып бетерә алырлармы-юкмы – әлегә әйтү кыенрак. Ник дигәндә, криптовалюта белән эш итүче иң зур финанс пирамидалары җимерелгән беренче очрак әле бу. Моңа кадәр беребезнең дә мондый очрак белән эш иткәне булмады. Хокук сакчылары өчен дә үзенә күрә сынау булды бу.

:: Гади халык финанс пирамидаларына бәйле бу вакыйгалардан нинди сабак алырга тиеш? Кабат искәртеп үтегезче.

– Финанс пирамидалары корбаны булмас өчен, иң беренче чиратта, мондый шикле оешмаларга борыныңны тыкмау хәерле. Машина йөртә белмәсәң, рульгә утырып юлга чыга алмыйсың. Йөзә белмәсәң дә, суга керүнең мәгънәсе юк. Монда да шул ук хәл. Инвестиция, икътисад, криптовалюталар өлкәсенә кагылышлы гади генә әйберләрне, кагыйдәләрне белмисең икән, язмышыңны сынарга кирәкми. Финанс пирамидаларында бик күп акча югалткан кешеләрнең күбесе – әнә шул рәвешле бу өлкәдә бернинди белеме, күзаллавы булмаган килеш, алдын-артын уйламыйча, акчасын суга салган кешеләр. Араларында финанс пирамидасына акча кертү өчен бик зур суммада кредит алучылар да шактый. Бу очракта иң отышлы юл – үзеңне банкрот дип тану. Әмма монда мәсьәләнең икенче ягы да бар. Әйтик, кеше банктан 1,5 миллион сум кредит алып, аның исемендә шул ук суммага җыела торган милке булса, үзен банкрот дип игълан иткән очракта, ул бу милкеннән колак кагачак. Аны сатып, шуннан кергән акчага кешенең банкка булган бурычын каплаячаклар. Шуңа күрә теләсә нинди юл белән эш итүче кырыгалдарлар корбаны булмас өчен, иң беренче чиратта, беркатлы булмаска, җиңел акчага кызыкмаска кирәк. Ниндидер җитди карарга килгәнче, җиде кат үлчәп, бер кат кисүдән дә яхшысы юк. Ташламалы шартларда вәгъдә ителгән әйберләргә кызыгырга, интернетта язылган бар нәрсәгә дә ышанырга ярамый. Кырыгалдарлар күп очракта кешенең әнә шул игътибарсызлыгыннан файдалана.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Россиядә яшәүче һәр алты кешенең берсе телефон аша эш итүче мошенник корбаны булган. Superjob порталы уздырган сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтә. Тикшеренүдә катнашкан респондентларның 11 проценты шул рәвешле үз гомерендә бер тапкыр гына алдануын, 5 проценты исә берничә тапкыр авызы пешүен әйткән. Хатын-кызлар ир-атларга караганда ешрак алдана икән. Сораштыруда катнашучыларның 13 проценты телефонына көн саен шикле номерлар шалтыратудан зарланган. Респондентларның 21 процентына мондый шалтыратулар – атнага берничә тапкыр, 23 процентына айга берничә тапкыр килә икән.

Шөгыль

КУЛ ЭШЛӘРЕМДӘ – ЯШЬЛЕГЕМ

Аның кул эшләрен Кытайдан да килеп алалар. Өен әле дә үзе бәйләгән урындык япмалары, мендәр тышлары, кашагалар бизи. Әгерҗе районының Салагыш авылында гомер итүче Кафия Тукаева 80 яшендә дә кулыннан энә-җепне төшерми. Әнә шулай, эш белән ял итәм, ди ул.

– Сугыш башланганда миңа 3 яшь булган. Әтине сугышка алып киттеләр. Әнием Зәкия 4 яше тулмаган абыемны һәм мине кочаклап, елап кала. Кызганычка, әтиебез яуда башын сала. Әти дип әйтә алмыйча, башкаларга көнләшеп үстем, – ди ул. – Әнием безне кеше итәр өчен бик тырышты. Ул озын гомерле булды. 100 яше тулырга 3 ай калган иде. Кадерләп яшәттем. Менә хәзер әниемнең хәер-догасында рәхәт яшим. Шөкер, абыем исән-сау, матур гына гомер кичерә.

Кафия апа әнисенең язмышын кабатлый. Ире иртә үлеп китә. Өч баласын кеше итәр өчен бар көчен куя. Кул эшләре тотып, күңелен ял иттерә, дөнья мәшәкатьләрен онытып тора.

– Ирем белән өч бала үстердек. Улым Рафаил – Ижауда, Венерам авылыбыз мәктәбендә укыта, Марс улым Казанда яши. Бөтендөнья татар конгрессында эшли ул. Төркиядә укып кайтты. Казанда университетта укыган чагы иде, 3 нче курста чакырып алдылар. Марсның хатыны – Кытайдан, Гөлчәһрә исемле. Шулкадәр матур итеп Тукай телендә сөйләшә, – ди ул.

Кафия апаны кул эшенә әбисе Гыйльмениса өйрәтә. Ул да кул эшләренә бик оста була.

– Мин эшкә тиз өйрәндем. Осталыгымны күреп, авыл кешеләре йомыш белән килә башлады. Әкренләп аларга чигә, тегә башладым. Бервакыт сыйныф җитәкчем мине кибеткә алып барып, тукыма алып бирде. Шул чакта шундый сөенгән идем. Ул тукымадан ни генә текмәдем. Авыл кешеләре теккән эленке, чаршауларымны бик яратты. Кешегә чигеп биргән кашагаларым да 100 метрдан артканддыр. Чиккән сөлгеләрем күргәзмәләрдә йөрде. Берсе Төркиядә дә зур бәя алган иде, – ди ул.

Кафия апа әле дә тик утырмый икән. Җәйләрен кул эшенә вакыт җитмәсә дә, кышын кич утырабыз, ди.

– Рәхәт тормышта яшим. Рафаил улым еш кайтып тора. Әле бергә кул эшләремне барладык. Сандыкны ачтым да, болар бит минем яшьлегем, дим. Күңелем тулды. Күз алдыннан бар гомерем узды, – ди ул. – Кызым Венера көн дә хәлемне белә. Мәктәптән кайтканда кереп чыга. Аны чәй куеп каршы алам. Марс улымның эшләре республика халкына да таныш. Аның белән бик тә горурланам. Авылдашларымның хөрмәте, рәхмәте, әниемнең ризалыгы белән рәхәт яшим, тормышым җиңел булмаса да, картлыгым бик бәхетле.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының 25 нче утырышы 8 октябрьдә узачак. Утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республика парламентына еллык Юллама белән чыгыш ясаячак. Чара Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында иртәнге 10.00 сәгатьтә (Ирек мәйданы, 3 й.) узачак. Иртәнге сәгать 10нан теле һәм радиотрансляция оештырыла.

Дәүләт Советы депутатларын теркәү иртәнге 8.00 сәгатьтән башланачак.

Белешмәләр өчен телефон: 276-63-62.

ПАРЛАМЕНТ ТЫҢЛАУЛАРЫ БУЛА

11 октябрь көнне Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Кече залында «2022 елга һәм пландагы 2023, 2024 елларга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты буенча парламент тыңлаулары үткәрелә. Чара 14.00 сәгатьтә башлана.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында **(https://gossov.tatarstan.ru/)** танышырга мөмкин.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, 1990–1995 елларда Татарстан Югары шурасы депутаты, «Мирас» тарихи-мәдәни фонд җитәкчесе

Җәмил САФИУЛЛИН

вафат булу сәбәпле, аның тормыш иптәше, язучы, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмованың авыр кайгысын уртаклаша. Мәрхүмнең туганнары һәм якыннарына сабырлык тели. Җәмил әфәнденең урыны оҗмахта булсын. Иннәлилләһи вә иннә иләйһи раҗигун!

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Оператив бүлекчәләр эшчәнлеген тәэмин итү буенча баш идарәсе» федераль казна учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлеге башлыгы урынбасары, эчке хезмәт полковнигы **Азарскова** Лилия Айрат кызына; «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Оператив бүлекчәләр эшчәнлеген тәэмин итү буенча баш идарәсе» федераль казна учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлеге башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Куприянов** Олег Михайловичка; «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү үзәк дирекциясе структур бүлекчәсе – Горький җылылык һәм су белән тәэмин итү дирекциясенең Ижевск территориаль участогы слесаре-ремонтчысы **Галиәхмәтов** Данил Садыр улына; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Зиньков** Андрей Николаевичка; «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең самбо буенча тренеры **Шәрифҗанов** Марат Рәис улына; «Татарстан – яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәтенең Лениногорск территориаль бүлекчәсе Советы рәисе **Мишин** Илья Ивановичка; Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Түбән Кама бүлеге башлыгы урынбасары **Сенников** Сергей Юрьевичка; Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Балтач һәм Кукмара районнары буенча муниципальара бүлеге башлыгы **Шакирова** Рәсимә Габдерәшит кызына; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе дәүләт мөлкәтенә идарә бүлеге баш киңәшчесе **Ермохина** Ирина Александровнага; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге баш белгече **Бакирова** Мария Рафаэль кызына; «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы гражданлык-хокукый дәгъвалар бүлеге башлыгы, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Вәлиуллин** Булат Илшат улына; Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре: Чаллы шәһәренең 2 номерлы суд приставлары бүлекчәсе башлыгы – өлкән суд приставы, эчке хезмәт лейтенанты **Имаев** Рәмис Рәис улына; Арча һәм Әтнә районнары буенча суд приставлары бүлекчәсе башлыгы – өлкән суд приставы, эчке хезмәт өлкән лейтенанты **Лотфуллин** Алмаз Камил улына; «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Халыкара мөнәсәбәтләр һәм Көнчыгышны өйрәнү югары мәктәбенең халыкара мөнәсәбәтләр, дөнья сәясәте һәм дипломатия кафедрасы доценты **Вәлиева-Хәкимова** Римма Рафаэль кызына; **«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Физика институтының ике тапкыр Советлар Союзы Герое очучы-космонавт А.А.Леонов исемендәге Казан федераль университеты планетарие коллективына**; Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы **Әхмәров** Айрат Фәргать улына; Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының икъдисад, дәүләт заказын урнаштыру һәм түләүләрне администрацияләү бүлеге башлыгы **Корбанов** Азат Шәйхетдин улына; «Чишмә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш ветеринария табибы (Татарстан Республикасы Актаныш районы) **Әхмәтов** Илназ Ирек улына; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе ветеринария куркынычсызлыгы һәм дәүләт күзәтчелеге Апас территориаль бүлеге башлыгы **Сафин** Фиргать Мәсгут улына; 2129-П хәрби часте «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты контролеры **Гомәрова** Даниэля Рафикъ кызына; 2129-П хәрби часте «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты өлкән контролеры **Хилинин** Глеб Викторовичка; Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының оборона комплексы бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Камалова** Гөлнара Марсель кызына; «РЕМОНТСТРОЙСЕРВИС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең агач эше остасы **Лашков** Вадим Александровичка; «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең Кама аръягы территориаль бүлеге директоры урынбасары **Надыршин** Айрат Рашат улына; «Төзелеш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең балта осталары бригадиры **Шәмсетдинов** Габдулхай Габдулла улына; «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе Татарстан Республикасы буенча филиалының Азнакай район бүлеге башлыгы **Хәсәншина** Маргарита Рамазан кызына; «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең хакыйкый әгъзалары: **Ильясов** Әхәт Вахит улына; **Таһиров** Индус Ризак улына; **Хәмидуллин** Филзә Гариф улына; **Чабдаров** Шамил Мидхәт улына; «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе баш бухгалтеры **Нәфикова** Зөһрә Вазыйх кызына; «Озон Волга» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең сыйфат төркеме җитәкчесе **Галибаев** Рафаэль Наил улына; «Ромекс-Кубань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте әйдәүче инженеры-геодезисты **Мәгъфуров** Айгиз Ралиф улына; **«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе коллективына Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Нурлат-информ» филиалы баш бухгалтеры **Әбҗәббарова** Миңнегөл Мингәрәй кызы; мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен Чаллы шәһәренең «4 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Әхмәтшина** Нәфисә Исхак кызы; күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Оператив бүлекчәләр эшчәнлеген тәэмин итү буенча баш идарәсе» федераль казна учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлеге башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Моратов** Марсель Марат улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республикада телевидение һәм радио өлкәсен үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе өчен «Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасының радио-телевидение тапшыру үзәге» филиалы «Тәтеш» цехы башлыгы **Мостаев** Венер Мөхәммәт улы; республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Россия җыелма спорт командаларын әзерләү үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Чаңгы ярышлары буенча Россия Федерациясе җыелма командасы өлкән тренеры **Перевозчиков** Олег Орестович; мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Сөйләмендә кимчелекләр булган балалар өчен төркемнәр оештырылган катнаш төрдәге 78 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире **Ризванова** Әлфия Кашбулгаян кызы; актив иҗтимагый эшчәнлеге, республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүгә өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы Советы әгъзасы **Хисаметдинов** Фәрит Миргазим улы; күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «САИФ» хосусый сак оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте дирекциясе директоры урынбасары **Аверьянов** Григорий Александрович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты җитәкчесе **Хәсәнов** Марат Сабир улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Чаллы шәһәренең «77 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Әхмәтшина** Татьяна Ивановнага; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Әлки урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тормыш иминлеге нигезләре укытучысы-оештыручысы **Билалов** Рафас Әбрар улына; Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының 5 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең инглиз теле укытучысы **Булатова** Лилия Шәйхразый кызына; «Кукмара аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының уку-укыту эше буенча урынбасары **Ганиев** Раил Миннераниф улына; Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Ю.А.Гагарин исемендәге 3 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Гыйльметдинова** Флера Хәмзә кызына; Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Апас урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Зыятдинова** Гүзәлия Сәгыйть кызына; Төмән өлкәсе Төмән муниципаль районының Х.Х.Якин исемендәге Шыкча урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Муллачанова** Гүзәлия Хәлил кызына; «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең мәктәпкәчә тәрбия буенча методисты **Орехова** Валентина Ивановнага; Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «7 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Хәмитов** Руслан Витальевичка; Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «4 номерлы Зәй урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Хуҗина** Гөлнар Габделхак кызына; Казан шәһәре Яңа Савин районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 89 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Белова** Татьяна Алексеевнага; Казан шәһәре Совет районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 86 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Галиева** Гөлназ Ринат кызына; Казан шәһәре Совет районының «8 номерлы гимназия – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Гыйрфанетдинова** Наталья Михайловнага; Казан шәһәре Совет районының «109 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире **Комкова** Венера Закир кызына; Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «37 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Орлова** Марина Владимировнага; Казан шәһәре Идел буе районының «Мәктәптән тыш эш үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Ремизова** Марина Павловнага; Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «14 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология укытучысы **Сибгатуллина** Римма Равил кызына; Казан шәһәре Яңа Савин районының «16 номерлы балалар музыка-хор мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең хор дисциплиналары укытучысы **Ткаченко** Миңсылу Марс кызына; Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «119 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Фадеева** Татьяна Петровнага; Казан шәһәре Совет районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 84 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Фәйзиева** Гүзәл Данил кызына; Казан шәһәре Вахитов районының «289 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе **Хәнәфиева** Равилә Габдерәүф кызына; Казан шәһәре Совет районының «93 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең география укытучысы **Шлямина** Ирина Борисовнага; Казан шәһәре Яңа Савин районының «177 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының уку-укыту эше буенча урынбасары **Яндаева** Люция Фәридан кызына; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Күгәрчен урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Закирова** Тәнзилә Әсәтулла кызына; «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Ачасыр төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Замалиева** Асия Габбаз кызына; Казан шәһәре Совет районының «394 номерлы татар телендә тәрбия һәм белем бирелә торган катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе укытучы-логопеды **Төхвәтуллина** Гөлшат Нургали кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы **Бәдретдинов** Марс Сарыйм улына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Әйдә инде, авылдаш

Ике шешә аракы алырга дип кибеткә чыккан идем. Аракы сүзен ишеткәч, үзен зыялыга санаучылар тиргәшергә дә мөмкин инде. «Язучы! Аракы сатып ала!» – дип әйтергә. Ни дип җаваплыйм инде? Әйе, язучы ул әле багана тишеге дә чокый, җир дә сөрә, сарай да ясый… Аракы алу мактаулы күренеш түгел, әлбәттә. Тик бөтен нәрсә кыйммәт чорда кайберләрен арзанайтасы, «бер ярты»га эшләтәсе килә. Ә ул кайвакыт ике шешә булып китә…

Вәт, мин менә шул «бер ярты»га эшли торган кешеләрне сыйлар өчен ике шешә алырга чыккан идем.

– Я, кайсыгызның чираты? – ди кибетче, безнең өстән күз йөгертеп. Авыл хатыннары үзара гәпләшеп басып тора инде. Һәм мин. Карашы миңа туктала.

– Кызлар алсын, – дим мин.

Кызлар миңа каршы төшәләр:

– Ир кеше алып китсен…

– Тем более язучы, – ди берсе. – Аны чиратта тотасыңмыни?

Кызларның берсе бөтенләй көтелмәгән тема ача:

– Марат абый, ә «Кайту»ны кайдан алдырып була?

– Ул бит электрон вариантта, – дип акланам, – интернеттан инде.

Ә авылдаш үзенекен итә:

– Кәгазь варианты кирәк. Безнең өчен генә…

Аны башкалар да элеп ала:

– Ну, кыен безгә электрон вариантта уку, Марат абый…

Мин үземчә уйлаган булам инде, электрон вариантта укуның бер кыенлыгы да юк, дим. Ул хәтта кәгазь китаптан да яхшырак әле. Төнлә дә укырга мөмкин. Беркемгә бер зыяны тими. Хәтта тавыш белән уку мөмкинлеге дә бар… Соңыннан аңлыйм инде үземнең ялгышуны. Син нәрсә турында сөйлисең? Мондый җайланмалар 10–20 мең сум тирәсе тора. Кем ала андыйны?! Электрон китап турында сөйләгәндә, кеше телефоннан укып була торган әйберләр турында әйтә бит. Минекеләр телефоннан да әйбәт укыла. Яхшы программа гына табарга кирәк.

– Кәгазьдә чыгарып булмыймы соң?

Була. Алар чыгып та тора бит инде. Хәтта туктаусыз рәвештә дип әйтергә мөмкин. Тик аларны һәрвакыт алып торалар. Кеше укыган өчен язам бит инде…

– Гафу итегез инде, кәгазь китапларның күбесе үземдә дә юк… – дип акланам.

Чынлап та шулай. Күп очакта мин үз китапларымны үзем дә эзләп йөрим һәм, гадәттә, бик зур бәягә сатып алам.

– Хет безнең өчен… Авылдашларың өчен… – диләр теге ханымнар. – Без аларны сатып алыр идек. Без чиратлашып булса да укыр идек.

– Хет авыл китапханәсенә… Берничә данә генә…

Китапханә турында уйларга кирәк. Җибәргәнем бар инде минем. Тик ул китаплар ярты юлда таралып бетә торгандыр. Үз кулың белән тапшырырга кирәк икән. «Менә бу китаплар сезгә, авылдашларым! Укыгыз рәхәтләнеп», – дип әйтергә. Тик ул китапларны миңа нәшрият бирми. Урындагы хакимият тә алырга атлыгып тормый. Шулай булгач, фәкать үз акчама гына алып кайтып бирә алам. Юк, әле аның анысы да катлаулы икән… «Зарарсыз әдәбият» икәнен исбатларга кирәк… Әллә ничә җирдә пичәт суктырырга…

Теләгән һәр кешегә кәгазь китап итеп чыгарып бирерлек нәшриятың булсын иде, ди уйлыйм мин. Хет үзеңнең туган авылыңда булса да китапханә оештырасы иде. Анда минем китаплар булсын. Һәм мин яратып укыган язучыларныкы. Бер карасаң, бу бик кыен да түгел инде. Теләк кенә кирәк. Һәм акча гына. Акча… Гына… Бу заманда акча беркайчан да «гына» булалмый. Чөнки мин татар гына. Гади язучы гына.

Шулай уйланып кайтканда кылт итеп ниндидер фикер туа.

Менә мин ике шешә аракы алып кайтып киләм. Мин аны дөньяның бөтен почмагында да алалам. Ә үз китапларымны алалмыйм. Хәтта сатып та. Бер мин генә түгел, бөтен язучы да шундый. Шулай булгач, татарча китап укучылар бүген аракы эчүчеләрдән дә түбәнрәк хәлгә куелган сыман булып тоела.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

СЕЗ – ДӨНЬЯНЫҢ КҮЧӘРЕ

5 ОКТЯБРЬ – ХАЛЫКАРА УКЫТУЧЫ КӨНЕ

Элек тә дөнья укытучы тирәсендә әйләнсә, бүген дә шулай. Аларны берни дә – роботлар да, компьютерлар да алыштыра алмый. Укытучы кадерен әти-әниләр читтән торып укыганда яхшырак аңлый башлады кебек. Мәктәпкә кайчан укытырга кайтасыз инде, без сезне бик сагындык, дигән сүзләр аларның кирәклеген тагын бер кат раслады. Ә сез укытучыларыгызны сагынасызмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бибинур ХӨСНУЛЛИНА,
Казанда яшәүче 101 яшьлек укытучы:

– Укучыларым бәйрәмнәрдә, Укытучы көнендә генә түгел, башка вакытта да хәлемне белешеп торалар. Элек открытка җибәрсәләр, хәзер телефон заманы бит. Шалтыратып котлагач та, бик сөенәм. Димәк, хезмәтем бушка китмәгән. Мин Кама Тамагы районының Кыртапа авылында тудым. Үземнең укытучыларымны бик яхшы хәтерлим. Беренче укытучым Әминә апа язарга, укырга өйрәтте. Эре хәрефләр белән язылган бик зур бер китап бар иде. Барыбыз да шуннан укыдык. Дәфтәрләр юк, иске китап араларына язып укый идек. Барый абый Ганиев – тарих, география фәннәре укытучысы. География укытучысы булып китүем аңа бәйле. Сыйныфта тыңламый торган бер генә бала да юк иде.

Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Спас педагогика техникумына укырга кердем. 1938 елда юллама буенча Югары Ослан районының Мәмәтхуҗа җидееллык мәктәбенә эшкә җибәрделәр. Миңа үземнән дә озынрак 4 нче сыйныф укучыларын укытырга туры килде. Алар – 16. Миңа «апа» дип дәштеләр. Яныма килеп: «Апа, бераз усалрак булыгыз, безне куркытыр өчен чыбык алып керегез, яме», – дип әйтүләре истә калган. Ничек чыбык алып керим инде, безне кыйнарга өйрәтмәделәр, ди идем. Усал була алмыйм, педагогика ысуллары андый түгел. Үзең яхшы булсаң, укучыларың да шундый булачак, дигән кагыйдәдән беркайчан да читкә тайпылмадым.

Васил ШӘЙХРАЗЫЕВ,
Татарстан Премьер-министры урынбасары:

– Укытучы һөнәр генә түгел, аны гаиләнең бер зур кешесе, туганы дип әйтергә була. Башлангыч сыйныфта Римма апа белән Вәли абый белем бирде. Вәли абый бакыйлыкка күчте, урыны оҗмахта булсын. Урта белем алганда, укытучылар күбәйде. Аларның барысы да кадерле. Ник дигәндә, төпле белем дә, тәрбия дә бирделәр. Элек тә укытучы һөнәрен зурладык, хәзер дә олылыйбыз. Ул – остаз. Без аны шулай дип атарга тиеш. Бүген мәктәпне белем бирү урыны дип кенә карасак, дөрес булмаячак, югалтулар да күбрәк булачак. Кошның ике канаты булган кебек, белем белән тәрбия икесе дә тигез булырга тиеш. Август киңәшмәсендә туган телдә укыту мәсьәләсе дә күтәрелде. Әти-әниләр балаларын туган телдә укытырга оялмасыннар иде.

Илсур ҺАДИУЛЛИН,
Татарстанның мәгариф һәм фән министры:

– Мәктәп елларын, укытучыларны күңел аша уздырганда, кемнәр генә искә төшми. Аларның күбесе бакыйлыкка күчте инде. Без Совет системасында укыдык, әхлак, тәртип көчле иде. Кеше башына басып йөрү дигән әйбер булмады. Олыны – олы, кечене кече итү канга сеңдерелде. Башлангычта укыткан мәрхүмә әнием Газзәбикә Хәбибрахман кызын еш искә төшерәм. Ул – мине тәрбияләгән, укыткан, тормышка әзерләгән кеше. Аны берничек тә әйтмичә калып булмый. Үз әниемне әйтү, бәлкем, бик килешеп тә бетмидер, әмма сүзләрем аның рухына дога булып барсын иде. Рус теле укытучысы Фәридә Харис кызы безне Казаннан килеп укытты, ул да мәрхүмә. Мин – химия укытучысы. Әлеге фәнне 7 нче сыйныфтан Халидә Нуретдин кызы укыта башлады, аннан Суфия Гаяз кызы дәвам итте, ул бүген лаеклы ялда. Аның такта янына басып химияне аңлатуы, һәр хәрәкәте бездә химиягә мәхәббәт уятты. Әлфия Вәлиевна, Рәис Габдрахманович, Рәфыйк Газизович, Петр Иванович, Валентина Петровна, сыйныф җитәкчем Лидия Семеновна, рус теленнән укыткан Җамалия Шәмсиевна… Алар бик күп. Мин укытучыларымны бәйрәм белән котлыйм. Исәннәренә саулык, күңел тынычлыгы, укучыларының тормышта югалмыйча яшәүләрен телим.

Василий ИВАНОВ,
Кукмара районы блогеры:

– Бәлкем, математика укытучысы Раушания апаның сүзен тыңлаган булсам, мин дә «кемдер» булган булыр идем. Ул миңа физика, математика юнәлеше буенча укырга барырга киңәш иткән иде. Алгебра, геометрия, физика фәннәреннән «4»ле һәм «5»ле билгеләренә генә укыдым. Янил училищесында Фаил абый юл хәрәкәте кагыйдәләрен бик яхшы итеп өйрәтте. Укытучыларның төрлесе бар. Минемчә, укытучы, иң беренче чиратта, баланы аермаска тиеш. Әти-әнинең дәрәҗәсенә, гаилә хәленә карап билге куючылар да бар. Бай гаиләсеннән булсаң, яхшы укымасаң да, әйбәт билге куярга мөмкиннәр. Гади кеше баласына «3»ле дә ярый.

Гүзәл УРАЗОВА,
Татарстанның халык артисты:

– Башта Пермь краеның Барда авылындагы гади генә мәктәптә белем алдым. Элек 3 нче сыйныфтан 5кә күчерәләр иде. Беренче тапкыр татар гимназиясе ачылгач, шунда укырга кердем. Иң сәләтле балаларны бәйге аша кабул итәләр иде. Иртән сәгать 7дә чыгып китеп, кичке 8–9ларда гына өйгә кайтып керә идем. Ничек бер дә арымаганмын икән дип аптырыйм. Җәяүләп йөри идек. Укытучыларны бик яраттым. Әлбәттә, аларның төрлесе булды. Һәрберсе без яхшы белем һәм тәрбия алсын өчен тырышты. Мөгаллимнәргә карата игътибарның күбрәк булуын телим. Алар – икенче әти-әни, балаларның киләчәге укытучылардан тора. Шуңа күрә укучылар да тәрбиялерәк булсын, әти-әниләр дә хөрмәт белән карасын иде. Иң яраткан укытучым – сыйныф җитәкчесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәймә апа Нургали кызы. Тукайның бөтен шигырьләрен белә идек, укымаган татар китабы, куймаган татар спектакле калмады. Шушы мәхәббәтне сеңдергән өчен рәхмәт аңа. Укытучылар сагындыра, күрешеп кенә булмый. Концертларда очрашканда, балачак, мәктәп еллары искә төшә.

Раил САДРИЕВ,
Буа Татар дәүләт драма театры җитәкчесе:

– Ятратканым да, яратмаганым да – укытучы. Үзем дә, әти-әнием, хатыным, аның бар туганнары да – укытучы. Бар дөньям укытучы белән тулган. 33 ел укытучы белән торам, үземне һаман дәрестә кебек хис итәм әле. Май аенда мәктәптән туеп китә идем дә, июль ахырында сагына башлыйм. Мәктәптә иң шук укучы идем. 1 нче сыйныфта директорга алып керсәләр, 11 нче сыйныфта куарга теләгәннәр иде. Педсовет җыеп, миннән: «Садриев, әгәр син шулай акыллы икән, укытучыларга укытыр өчен тәкъдимнәреңне яз әле», – диделәр. Ул минем ата-аналар җыелышларында сүгелгәннәрем, ул минем өйгә килгән укытучы… Андагы минем галәмәтләр… Мактанып әйтүем түгел, шул ук вакытта бүген мәктәпкә ярдәм итүче дә – миндер. Укытучы көне – безнең династия бәйрәме. Мөгаллимнәр – җәмгыятькә иң кирәкле кешеләр. Нигез бер генә кирпечтән тора, бер генә катлы була алмый. Укытучылар, табиблар – иң төп кешеләр, ә чиновниклар арадашчы гына. Әгәр баеп китсәм, аларга һәйкәл куяр идем. Яратмаган дәрестә, теләсә кайсы спектакльдә, киңәшмәдә 45 минут түзеп утыру – минем өчен фаҗига. Укытучыларым бит миңа һәр дәрес саен түзгән, барысы өчен дә рәхмәт аларга.

Лилия ГЫЙМАЗОВА,
«Ватаным Татарстан» газетасы журналисты:

– 10–11 нче сыйныфларда класс җитәкчебез Ринат Миннегаян улы Хәйруллин иде. Чамалыйсыздыр инде: җитлегеп килгән вакыт, элек гадәти күренгән нәрсәләргә йә ярсыган, йә бөтенләй игътибар итмәгән чор. Сабыйлыктагы самимилекнең тиребездән куба башлаган чагы. Тагын ике елдан яңа тормыш башлыйсы. Аңа өстәп, имтиханнар белән куркыталар. Рухың сынарга тора. Физик яктан да авыр. Һәрхәлдә, ул еллар шул яклары белән дә истә калган. Ринат абый безне яхшы аңлаган, күрәсең.

Ул ике ел эчендә булган вакыйгаларның барысын да санасаң, артык озакка китәр. 10 нчы сыйныфта җыелышып концерт куюлар турында сөйлим әле. Юк, беребез дә сәхнә кешеләре булмадык. Бәлки, «әлегә» дип өстәү хәерлерәктер бу урында. Ләкин сәгать ярым, ике сәгатьлек тамаша күрсәтә идек. Якын-тирәдәге авылларга «гастроль»ләр белән дә йөрдек әле. Яшерен-батырын түгел, имтихан белән каткан башны бу бик җебетми күк тоела иде. Арылгандыр да инде. Ләкин кызык иде ул чаклар. Алты бөртекнең һәркайсында кимендә өч вазыйфа: җырчы, биюче, нәфис сүз остасы, музыка коралында уйнаучы, гимнаст, чәчтараш, визажист, стилист – бәлки, санап та бетермәгәнмендер. Идеядән алып аны тормышка ашыруга кадәр шактый көч түгелә. Гадәттә, идея авторы – бу процесста иң нык борчылучы кеше. Ринат абый тәкъдиме белән куелган бу концертлар аның таләпчән һәм принципиаль булуы аркасында да яхшы узды. Хәзер уйлыйм инде: элек ул миңа урыны-урыны белән кырысрак тоела иде (билгеле, шулай булырга тиешлеген аңлый идем үзем), бу аның безнең өчен үз балалары өчен борчылган кебек җан атуыннан булмаган микән?

Ринат абый безгә гел: «Уку белән генә чикләнмибез, балалар!» – дип әйтә килде. Ял итүнең ямен һәм тәмен күрсәтте. Бәлки, мин моны элек аңлап җиткермәгәнмендер. Кешенең табигате шундый бит инде ул. Ни генә булса да, тормышымда яхшы укытучылар шактый булды. Иң мөһиме, хәзер мин кайчандыр бүгенгемә өлеш керткән мөгаллимнәргә зур хөрмәт белән карыйм һәм чын күңелдән һөнәри бәйрәмнәре белән тәбриклим!

Васил ГАРИФУЛИН,
КФУның милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе:

– Мин Теләче районының Югары Кибәхуҗа мәктәбендә укыдым. Рус теле һәм әдәбиятыннан кечерәк сыйныфларда Равил абый Галәвиев укытты. Ул – мине журналистикага алып килгән шәхес. Замандында үзе дә район газеталарына языша иде. Мәктәптә стена газеталары конкурсын зурлап уздыра, бөтен балаларны шигырь, хикәя, мәкалә язарга җәлеп итә. Мин дә кече яшьтән шигырьләр, район газетасына мәкаләләр яза башладым. Равил абый аларны төзәтеп-редакцияләп кенә калмый, мәктәп машинкасында пичәтләп үк бирә иде.

Хәтеремдә, район газетасына берничә еллар буе бик актив язышкач, Сабадан мине «Җиңү байрагы» газетасына эшкә чакырырга дип редактор Хөснулла абый Шәфигуллин килгән иде. Мәктәп директоры Хәниф Мансурович Шаһиев бүлмәсенә чакырып сөйләштеләр. «Мин сигезенче класста гына укыйм бит әле», – дим. «Тугыз белән унны Сабада укып бетерерсең», – ди Хөснулла ага. Уйлап карарга булдым. Шунда мине Равил абый эзләп тапты. «Юләрләнмә, – ди бу. – Син анда бик тиз яначаксың. Сиңа әле төпле белем алырга, ныгырга кирәк. Урта мәктәп кенә түгел, университет тәмамларга, тормыш тәҗрибәсе тупларга кирәк. Шунсыз журналистикада эшләргә ярамый». Күндерде Равил абый. Сабага китәргә ризалашмадым. Дөрес эшләгәнмен икән, анысын үсә төшкәч кенә аңладым.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7405 данә
Гомуми тираж – 17243 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 344

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+